БАЛЫК, КАП

Читтән табышлы бизнес кебек күренсә дә, авырлыклары да шактый булып чыкты

> 2

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН

«Республикада төп макроикътисади күрсәткечләр буенча уңай динамика күзәтелә»

> 5

ТЫРЫШЛЫК ҖИТӘ

Биектау районының Дөбьяз мәктәбе укучысы Раян Шакиров рус теленнән имтиханда 100 балл туплаган

> 6

КАРИЕВТА – ПРЕМЬЕРА

«Әмма» һәм «тик»ләрне игътибарга алмаганда, «Йосыф» – матур спектакль...

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 85 (28858) | Шимбә | 18 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЙӨРӘК САЙЛАГАН ҺӨНӘР

19 июнь – Медицина хезмәткәре көне

Тыныч йоклаган чак сирәк. Саба районы Олы Шыңар авылында 37 ел фельдшер булып эшләгән Рузилә Мөхәммәтованың бу сүзләре белән гомерен шушы җаваплы хезмәткә багышлаган һәркем килешер. «Безнең һөнәрдә үз эшеңне ярату гына җитми. Аның белән көне-төне яшәргә кирәк. Фельдшер гомер буе кеше өчен борчылып яши. Кичтән берәрсе авырса, хәле ничек, төнне ничек уздырды икән, дип уйлап чыгасың», – ди ул.

Тумышы белән Оет авылыннан булган Рузилә Мөхәммәтованың яшьлеге укытучы белән табиб һөнәрләренең иң популяр чорына туры килә. Иптәш кызы укытучы һөнәрен сайлый, ул медицина юнәлешен үз итә. «Күңелемә дә, холкыма да иң туры килгән һөнәр кебек тоелды ул миңа», – дип искә ала ул елларны әңгәмәдәшем. Казан медицина көллиятендә фельдшер-акушерлык белгечлеген үзләштергән кыз күрше Олы Шыңар авылына фельдшер булып эшкә кайта.

Ул чорда 1100дән артык кеше яшәгән авылның төпләнеп калган үз фельдшеры булмый. Ел саен 3–4 белгеч алышынып торган. «Мин йомшаграк, сабыррак булганга күрә шушы эшемдә калганмындыр инде. Биш чакрым ераклыктагы күрше авылда гына әти-әнием яшәгәч тә күңелемә тыныч, рәхәт иде», – дип елмая Рузилә апа.

Авылга кайтып, бер ел эшләгәч, Рузилә ханым шушы авыл егете Марсель абый белән гаилә корып җибәрә. Ике ул һәм бер кыз тәрбияләп үстерә алар. Яшерен-батырын түгел, табиб, фельдшер һөнәрен сайлаган кеше белән гомер итү җиңел түгел. Кеше гомере, сәламәтлеге сагында торган бу һөнәр ияләренең алы да, ялы да юк. Авыл җирендәге фельдшерларга икеләтә кыен. Җаваплы эшең белән беррәттән, гаилә тормышын да, хуҗалык, бакча эшләрен дә җиренә җиткереп алып барырга кирәк. Әмма якыннары Рузилә ханымга һәрчак терәк була. «Гаиләм дә һөнәремне аңлап кабул иткәч, бик рәхәт», – ди ул.

Өч дистә ел гомерен сәламәтлек сагына багышлаган фельдшерның үткән белән бүгенгене дә чагыштырырлыгы бар. «Аерма җир белән күк арасы инде. Элегрәк авылдагы юллар үзәккә үтә иде. Даруны да үзебез алып кайттык. Хәзер аны медпунктка китереп бирәләр. Берничә авылга хезмәт күрсәтүче ФАПларга мобиль машиналар да бирелә. 65 яшьтән өлкәнрәкләрне районга диспансеризация уздырырга, флюорография үтәргә алып барасы булганда социаль яклау идарәсеннән машина сорый алабыз. Бу махсус программа буенча эшләнә», – ди ул.

Рузилә Мөхәммәтова үзе авырулар янына велосипедта җилдерә икән. Ник дигәндә, ул хезмәт күрсәткән Олы Шыңар һәм Кече Шыңар авылларының арасы бик якын. Элегрәк Түлешкә авылы да аларга караган. Ләкин хәзер бу авыл беткән. Рузилә ханым бүген барлыгы 726 кешегә хезмәт күрсәтә. Хәзерге заманда фельдшерларның эшен бермә-бер җиңеләйткән тагын бер иң зур өстенлекне атый ул. Өч ел элек теле-ФАП программасы буенча да эшли башлаган алар.

– Авыру кешене үзебезгә алып килеп, видеоэлемтә аша райондагы табиб белән турыдан-туры онлайн консультация уздырабыз. Сабага барып торасы да юк. Шушында ук йөрәген дә яздырабыз. Аның нәтиҗәләрен райондагы табиб та, Казандагысы да карый ала. Бу инсульт, инфаркт очракларын алдан кисәтеп, кешегә тиз арада тиешле ярдәм күрсәтергә мөмкинлек бирә, – ди.

Фельдшер кешегә авыруларны дару белән генә түгел, сүз белән дә дәваларга туры килә. Йөрәксенмичә куркып торган кешене тынычландырасы, кирәрәген үтемле сүз табып күндерәсе дә бар. Үзеннән-үзе психологка да әверелэсең. Моңа өстәп әле фельдшердан тәвәккәллек, кыюлык та сорала. «Җиңелчә генә киселү-бәрелү, баланың борынына, колагына кергән ят әйберне алудан башлап кеше гомерен саклап калуга кадәр – барысы да безнең өстә. Фаҗигале очракларда да кешене иң беренче без күрәбез, без ярдәм итәбез. Шушы бер йөрәккә барысын күтәрергә кирәк», – ди Рузилә ханым үзе дә.

Әмма бу юлны сайлавына һич кенә дә үкенми. Кешеләргә ярдәм итә алуы, кемгәдер икенче гомер бүләк итүе, чын күңелдән әйтелгән рәхмәт сүзләре бөтен авырлыкларны оныттыра, ди ул. Үзенә алмашка да үз эшенә җаваплы караган яшьләр килүен тели тәҗрибәле белгеч. «Хәзерге яшьләр без түгел: аларның дөньяга карашы да, табигате дә башка. Безне бер урынга эшкә билгеләгәннәр икән – шунда гомер буе эшләдек. Хәзер яшьләр исә эшне алмаштырып карый, яхшырагын табарга тели. Безнең һөнәрдә эшнең ни дәрәҗәдә күп булуын күрәләр. Казанда фельдшер булып эшләп, өч тапкыр күбрәк хезмәт хакы алып булуын да яхшы аңлыйлар, – ди Рузилә Мөхәммәтова. – Үзеңне аямыйча, кеше өчен яши торган һөнәр бу. Безнең эштә бар нәрсәне секундлар хәл итә. Әнә шуңа әзер булырга кирәк».

Сырхауханәләр яңара

Быел Татарстанда «Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты буенча төбәкнең сигез проекты гамәлгә ашырыла. Моның өчен 4,2 миллиард сум акча каралган. Икътисад министрлыгы мәгълүматларына караганда, акчаның зур өлеше – 2,4 миллиард сум сәламәтлек саклау чылбырының беренчел буыны – амбулатория-сырхауханәләрне яңартуга тотылачак. Шулай итеп, быел Питрәч һәм Лениногорск районнарында – амбулаторияләр, Казан һәм Яшел Үзәндә – сырхауханәләр, Әлмәт районында – педиатрия үзәге, 29 фельдшер-акушерлык пункты төзеләчәк. Моннан тыш районнарда – 12 сырхауханә, Зәй һәм Кайбыч районнарында – хатын-кызлар консультацияләре, Лениногорск районы үзәк хастаханәсенең терапия бүлеге капиталь төзекләндереләчәк. Шул ук вакытта беренчел буын медицина оешмаларына 17 автомобиль һәм 1256 берәмлек җиһаз, йөрәк-кан тамырлары авыруларын булдырмау өчен дарулар сатып алыначак. Инде килеп, профилактик тикшерүләр үткәреләчәк, табибларга социаль һәм дәүләт ярдәме күрсәтеләчәк.

Шулай итеп, илкүләм проект кысасында чараларны гамәлгә ашыру сырхауханәләрнең 95 процентын заманчага әйләндерү, республикада яшәүчеләрнең 55 проценттан артыграгына медицина тикшерүе уздыру мөмкинлеге бирәчәк.

Укытучыларга – грант

Татарстанда татар теле һәм әдәбияты буенча 13 укытучы олимпиада призерларын әзерләгән өчен 115әр мең сум күләмендә грант алачак. Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, быел грант бәйгесендә катнашу өчен 52 гариза тапшырылган, 13 кеше җиңгән. Аерым алганда, Актаныш гуманитар гимназия-интернаты, Саба аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче интернат-мәктәбе, Арча 6 нчы урта мәктәбе, Балтач районы Норма урта мәктәбе, Кукмара 3 нче урта мәктәбе укытучылары грант алачак. Бәйге 25 майдан 10 июньгә кадәр үткәрелгән.

Урман утырталар

Татарстанда «Урманнарны саклау» федераль проекты һәм «Экология» илкүләм проекты буенча 549 гектар мәйданда урманнар чистартылып, тәртипкә салынган. Барлыгы 2098 гектар мәйданда эшләр башкарырга туры киләчәк.

Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы оешмалар белгечләре быел җәмгысы 1521,1 гектар мәйданда урманнарны яңарткан. Шуның 1412,5 гектарында – киселгән, корыганнары урынына, 104,6 гектарында буш җирләргә яшь үсентеләр утыртылган, 4 гектарында урманны калынайту эшләре башкарылган. Министр Равил Кузюров әйтүенчә, яраксызга әйләнгән агачлар мәйданының 76 процентына яңалары утыртылган инде. Барлык эшләр башкарылгач, бу күрсәткеч 140 процентка җитәчәк. Проект буенча урманнардагы токымлы төп агачларның орлыклары да әзерләнә.

tatarstan.ru

Икътисад

Гаҗәп түгел, табигый

ТАТАРСТАН КАБАТ БИЗНЕС ӨЧЕН УҢАЙЛЫ ТӨБӘК БУЛУЫН РАСЛАДЫ

Бизнес кору уңайлы, ярдәм бар. Татарстан Россия субъектларының инвестицион климат торышының илкүләм рейтингында икенче урынны яулады. Сүз уңаеннан, республика дүртенче ел рәттән шушы позициясен саклап килә. Җиде ел дәвамында исә алдынгылар өчлегеннән төшми. Быел беренчелек – Мәскәүдә, өченче урында – Мәскәү өлкәсе.

Рейтингны Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча Стратегик инициативалар агентлыгы әзерли. Исемлек төзегәндә теге яисә бу төбәктәге бизнес-мохит анализлана, инфраструктура, кече эшмәкәрлеккә ярдәм чаралары исәпкә алына. Бу елдан субъектларга бәя бирү таләпләре саны 44тән 64кә кадәр артты. Димәк, алдынгы һәм лаеклы булуны дәлилләр өчен тагын да күбрәк тырышырга кирәк.

Рейтингны шушы көннәрдә Санкт-Петербургта узган халыкара икътисади форумда агентлык җитәкчесе Светлана Чупшева тәкъдим итте. Ул республиканы кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм бизнес өчен кирәкле чараларның нәтиҗәлелеге буенча иң яхшы төбәкләрнең берсе дип атады.

Форум кысасында Россия Хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары Андрей Белоусов та Татарстан тәҗрибәсенә аерым тукталды. Вице-премьер сүзләренчә, республиканың мондый уңышка ирешүе (һәм берничә ел рәттән үз позициясен саклап калуы) бер дә гаҗәп хәл түгел.

Андрей Белоусов искәрткәнчә, беренчедән, Татарстанда бизнеска ярдәм итү инфраструктурасы үсеш алган. Технопаркларда, бизнес-инкубаторларда эш урыннары ил буенча уртача күрсәткечтән 10 тапкыр югарырак булуы моны дәлилли дә. Икенче сәбәп – бизнес алып баручыларга карата тикшерүләрнең кимүе. Әйтик, узган ел Татарстанда алар ил буенча уртача күрсәткечтән 2 тапкыр кимрәк үткәрелгән. Өченче сәбәп – инвесторларны бәяләү буенча җирле канун сыйфаты. Вице-премьер, бу җәһәттән Татарстан шактый зур нәтиҗәләргә иреште, ди.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, элек республика бизнес дучар ителгән тикшерүләр саны буенча тәнкыйть утына тотыла торган булган. Рейтинг та, Президент та вазгыятьнең үзгәрүен дәлилләде.

– Үзебезне бик үк матур яктан күрсәтми идек, тәнкыйтьләделәр. Әмма без контроль-ревизия һәм контроль-күзәтчелек органнары белән эшне кора алдык. Прокуратура белән берлектә бу эшне системага салдык. Бизнесның кәефе безнең өчен бик мөһим, – диде республика җитәкчесе.

Рейтинг нәтиҗәләрен Татарстан Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрит Габделганиев та шәрехләде. Аныңча, уртак тырышлык нәтиҗәсендә Татарстан Россиянең барлык төбәкләре арасында бизнеска административ басымны киметүнең иң зур дәрәҗәсен күрсәтте. «Эшмәкәрләрнең хокукларын яклау, ихтыяҗларын кайгырту бурычы тора. 2022 елның биш аенда миңа үзебезнең эшмәкәрләрдән 1508 мөрәҗәгать килде. 70 процент очракта без эшкуарларның мәнфәгатьләрен яклый алдык, калганнары буенча җентекле юридик консультацияләр бирелде», – диде ул.

Фәрит Габделганиев сүзләренчә, җирле эшкуарларны электрон сәүдә мәйданчыклары белән дуслаштыру эше дә хәл ителә. «Инфраструктураны үстерү, республикага электрон сәүдә, транспорт һәм логистика хезмәтләре базарының әйдәп баручы вәкилләрен җәлеп итү буенча эш башкарылды», – дип аңлатты бизнес-омбудсмен.

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Без – көчле халык һәм теләсә нинди авырлыкны җиңеп чыгачакбыз. Бу хакта илебезнең меңьеллык тарихы искәртә.

(Санкт-Петербург Халыкара икътисади форумы пленар утырышындагы чыгышыннан)

ТАТАРСТАНДА – АВЫЛ ИПОТЕКАСЫ

БАРЛЫГЫ – 2087

2020 елда >> **1256** / 2021 елда >> **789**

АВЫЛ ИПОТЕКАСЫННАН АКТИВ ФАЙДАЛАНУЧЫЛАР

Биектау >> **247** / Яшел Үзән >> **121**

Бурычлыларның мөлкәтен алалар

Ел башыннан бирле Татарстан приставлары бурычын түләмәүчеләрнең 1500гә якын күчемле һәм күчемсез милкенә арест салган. Хуҗасыннан алынган мөлкәтнең гомуми бәясе 420 миллион сумнан артыграк тәшкил итә.

Пристав, теге яки бу кешенең бурычын түләтү өчен, милкеннән мәхрүм итү хокукына ия. Әйтергә кирәк, әлеге чараның нәтиҗәсе шактый ук зур. Мәсәлән, Әлмәт районында яшәүче берәү «Hyundai Sonata» маркалы автомобиленә чикләү салынганнан соң 10 көн узуга, салымчылар алдындагы барлык бурычын (204,5 мең сумнан артык) түләгән. Машинасын аңа кире кайтарганнар. Шул ук вакытта Казанның бер фирмасы хуҗасы 6,5 миллион сумга якын бурычын түләмәгән. Аның арест салынган 2 машинасы – «Kia Rio» һәм «Renault Duster», аукционда сатылып, бурыч түләүгә китәчәк.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Капитализм: котылу эзләгәндә

Дөньяда инде дүрт гасыр буе диярлек капитализм тантанасы. Әлбәттә, Җир шары олы, илләр күп, әле кайдадыр феодализм да бетеп җитмәгән, ул гынамы, берничә илдә һаман да булса астыртын коллык яшәве хакында да язалар. Кайдадыр Амазония джунглиларында кыргый кабиләләр гомумән дә борынгы иҗтимагый стройда яшәп ята. Әмма дөнья илләренең абсолют күпчелеге капиталистик мөнәсәбәтләрне инде хәтсездән үз иткән. Мөнәсәбәтләр кайдадыр ярыйсы ук камил, кайда мәрхәмәтсез булган хәлдә дә, җиһан ул стройга инде ияләшкән, капитализмга нинди дә булса алмаш эзләми дә кебек.

Алмаш эзләмәгән тәкъдирдә дә, фикерле затлар арасында бүгенге глобаль капитализмны каһәрләүчеләр күп. Тик аңа алмашка менә шундыйрак җәмгыять, шундый бәйләнешләр туарга тиеш, диючеләр генә бөтенләй дә диярлек юк. Халыкның гына түгел, аналитикларның да күпчелеге ул хакта артык баш катырмыйча, вакыты җиткәч, яңа, үзгә җәмгыять автомат рәвештә яралыр, дигәнрәк уй белән яшәп ята булса кирәк. Имештер, дөнья, икътисади һәм иҗтимагый багланышлар гомер үткән саен үзгәрә тора, заманы килгәч, яңа, камилрәк формация тумый калмас. Капитализм да, үз дәвере өчен бер алгарыш буларак, үзеннән-үзе диярлек яралган бит, нигә кыбырсырга…

Капитализмны, әлбәттә, гадел, миһербанлы строй дип атап булмый. Хәтта бүгенгесен дә. Чөнки ул кешене кеше эксплуатацияләүгә, Маркс әйткән өстәмә түләүгә (прибавочная стоимость) корылган. Шулай да, әйткәнебезчә, ул үзенә кадәр булган иҗтимагый формация, стройлардан – өч мең елдан артыкка сузылган колбиләүчелек чорыннан да, унике гасыр буе яшәгән феодализмнан да «продвинутый»рак. Чөнки изү белән изү арасында аерма зур. Колбиләүчелек чорындагы изелүче кемнеңдер шәхси милке саналса, капитализмда ул, ялланып, хезмәт хакына эшләүче ирекле граждан. Алай гына да түгел.

Европа белән Төньяк Америкадагы, Азиянең Япония, Көньяк Корея, Тайвань кебек илләрендәге бүгенге капитализмны хезмәт кешесенә йөзе белән борылган адәм чырайлы капитализм дияргә дә мөмкиндер. Барысында да сигез сәгатьлек эш көне, хезмәткә лаеклы түләү, шактый көчле социаль яклаулар. (Дөнья капиталының котын ботына төшергән Октябрь инкыйлабы килеп чыкмаса, бүгенге капитализм, ихтимал, күпкә кырысрак, саранрак, кешелексезрәк булыр, гади халыкка саналганнарның барысына да тәтемәс иде.) Шул ук алман, француз әби-бабайлары пенсия акчасына рәхәтләнеп дөнья гизәләр, сәяхәттә йөриләр. Капитализмны фәлән-фәсмәтән, дип ялгышып та сүкми, каһәрләмиләр. Марксизм авторларыннан чыккан: «Фәлән процент табыш дигәндә капитал теләсә нинди җинаятькә әзер», – дигән мәгълүм формула ул дәүләтләрдә инде эшләми. Төньяк Европа илләрендәге «социалистик капитализм» турында әйткән дә юк.

Үткән язмаларның берсендә: «Җирдә бар тарафларда да «швед социализмы» кебек гадел җәмгыятьләр яралып, бер үк вакытта рухи якка да игътибар бермә-бер арткан очракта кешелек бәхетле һәм проблемасыз яшәешкә ирешер, андый «социализм» бүгенге капитализмга алмаш була алыр», – дигәнрәк фикер белдерелгән иде. Фикер көчендә кала. Чөнки Маркс әйткән, Европа өстендә йөргән коммунизм өрәге җисемгә әйләнә, материальләшә алмады. Бу аңлашыла да. Томас Мор, Кампанеллалардан башлап, Ленинга, гади халыкка кадәр хыялланган коммунизм адәм баласының холык-фигыленә, табигатенә туры килми чөнки. Бәндәләрне, антик юлбасар Прокруст кебек, бер калыпка салып тигезләү мөмкин дә, дөрес тә түгел. Кешеләр бер-береннән сәләт ягыннан да, хезмәткә мөнәсәбәт ягыннан да нык аерыла. Булдыклы, тырышлар бар, ата ялкаулар да беркая да китмәгән. Гыйлемгә табынганнар булган кебек, чи наданнар да җитәрлек. Ни өчен әле алар барысы да бертигез яшәргә тиеш? Җәмәгать милке дә бәндә психологиясенә туры килми – татар мәкале тикмәгә генә «уртак малны эт тә ашамый» дими.

Бәс шулай икән, бүгенгә иң кулай, «homo sapiens»ка иң туры килә торган мөнәсәбәтләр чыннан да капитализм белән социализмның синтезы тирәсендә ята булып чыга. Уңган-булган зат ниндидер җитештерү цехы, фирма ача, ә артык пошмас, килешү төзеп, аңа килеп яллана, ул биргән акчага разый икән – биредә бер гаделсезлек тә юк. Ялланучыны кәкре каенга терәтү, марксизм теориясендәге теге «прибавочная стоимость» кына билгеле калыптан чыкмасын.

Синтез дигәндә һич тә велосипед уйлап табасы түгел. Инде күптән конвергенция – бер-берсенә каршы тоелган ике иҗтимагый-икътисади стройны – капитализм белән социализмны кушу – икесеннән дә иң уңай якларны алып, аларны берләштерү хакында сүз йөри. Беренче булып аны практикада Ленин бабабыз кулланып караганы да мәгълүм. Социализм җиңеп тә, илдә халык тамагын туйдыруда кыенлык туа башлагач, ул Яңа икътисади сәясәт (НЭП) дигән юнәлеш игълан итә. Дәүләт сәүдәсе урынын яңадан вак сәүдәгәрләр ала, яңадан көлдән гөлгә әйләнгән кече бизнес яшь совет илен бәладән коткара. Туксанынчы елларда Кытай алган икътисади-сәяси курс – коммунистлар партиясе җитәкчелегендә капитализм төзергә алыну да үз нәтиҗәләрен күрсәтте. Ләкин Кытайдагы каты авторитар гибрид система тормыш сыйфаты ягыннан да, кеше хокуклары буенча да Төньяк Европадагыдан шактый аерыла. Һәм алар очрагында: «Илнең икътисади уңышлары, тамак туклыгы, өс бөтенлегенең бәясе, бәндә ирексез, ул дәүләт мәнфәгатьләре өчен булганда ташка үлчим», – диясе килә…

Бүгенге капитализм, аерым илләрдә аны кеше чырайлыга санап булганда да, шул ук монополияләр, шул ук финанс капиталы, халыкара картельләр, рибачылык белән яшәүче банклар. Ниндидер куркыныч албасты булмаган җәһәттә дә ул әлегә гөнаһлар җыелмасы булып кала. Табыш, аңа ымсыну гөнаһта тота аны. Икенче яктан алганда, капитал – фәнни-техник һәм технологик прогресс сәбәпчесе. Ачыш, алгарышларның табышны бермә-бер арттыруын исбатлыйсы түгел. Ләкин биредә дә каршылык бар: техник прогрессның аерым юнәлешләре табигатькә, аның аша кешенең үзенә дә зарарга эшли. Монысы да табышка бәйле хәл. Алгарыш-үсешне, аңа бәйле табышны исә властьның либераль юнәлештә булып, алышынып торуы, гражданнарның активлыгы, хокук-ирекләре дә тәэмин итә. Яңа тарихта күпме илләр буржуаз-демократик революцияләр аша үткән. Ягъни капитализм демократиягә дә мохтаҗ. Монысы аның күп булмаган уңай сыйфатлары арасында иң асылы түгел микән?

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ТӨНЬЯК КАЛАДАН – УҢЫШ БЕЛӘН

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Санкт-Петербургтагы очрашулары, эшлекле сөйләшүләре җомга көнне дә дәвам итте. Искәртеп үтик: республика Президенты бу көннәрдә Санкт-Петербург халыкара икътисади форумында катнаша.

tatarstan.ru

ДУСТАНӘ ОЧРАШУЛАР. Рөстәм Миңнеханов Казахстан Президенты Касым-Жомарт Токаев белән очрашты һәм аны Казахстан Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча референдумны уңышлы үткәрү белән тәбрикләде.

Сүз уңаеннан, быел Россия белән Казахстан арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләр оешуга 30 ел тула. «Бүген Казахстан – Татарстан өчен алдынгы чит ил партнерларының берсе. Уртак проектларны гамәлгә ашыруда һәрвакыт ярдәм итәргә әзер булуыгыз өчен рәхмәт», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Былтыр ике арадагы товар әйләнеше 629 млн долларны тәшкил иткән. Ике як та әлеге күрсәткечләрне арттыру һәм хезмәттәшлекне киңәйтү мөһимлеген билгеләп үттеләр. Очрашу барышында геологик тикшеренү проектын тормышка ашыру буенча килешү имзаланды.

Шушы ук көнне Рөстәм Миңнеханов Үзбәкстанның инновацион үсеш министры Иброхим Абдурахмонов белән очрашты. Республика җитәкчесе Үзбәкстан Президентына эшлекле мөнәсәбәтләрне арттыру юнәлешендә башкарган эше өчен рәхмәтен җиткерде, уртак проектларны тормышка ашырудагы уңышларны бәяләде.

Моннан тыш Рөстәм Миңнеханов Бәһрәйн Корольлегенең Россиядәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе белән очрашты.

Рөстәм Миңнехановның Төньяк башкаладагы форум кысасында Әстерхан өлкәсе губернаторы Игорь Бабушкин белән очрашуы узды. Ике як арасында хезмәттәшлек юнәлеше булып цифрлаштыру тармагы тора. Очрашу нәтиҗәсе буларак 2022–2024 еллардагы чаралар планы имзаланды.

ТОРМЫШ КАРТАСЫ. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Илкүләм түләү картасы системасы – НСПК» җәмгыяте генераль директоры Владимир Комлев белән уртак хезмәттәшлек турында килешү имзалады. Аерым алганда, сүз «Татарстанлы картасы» проекты турында бара. Аны быелдан ук гамәлгә ашыру күздә тотыла. Әлеге карта социаль әһәмияткә ия хезмәтләрне берләштерәчәк (җәмәгать транспортында йөрү, СНИЛС, иминият полисы һ.б.).

ИМПОРТКА АЛМАШ. Төньяк башкаладагы форум кысасында Татарстан Президенты «ROCKWOOL Russia» компаниясе генераль директоры Марина Потокер белән очрашты.

Әлеге компания үз эшчәнлеген 1909 елда Даниядә башлый. Җылылык һәм тавыш изоляциясе максатыннан кулланыла торган минераль мамык (каменная вата) җитештерә. Татарстанда урнашкан завод продукциясе республикада 16 зур объектның сәнәгать төзелешендә, шулай ук гадәти төзелеш эшләрендә дә файдаланыла.

– Катлаулы халыкара вазгыятькә карамастан, сезнең оешма безнең республикада эшен дәвам итә. «Роквул» «Алабуга» махсус икътисади зонасы вәкиле санала, – дип искәртте Рөстәм Миңнеханов.

Очрашуда республика җитәкчесе материаллар җитештерү юнәлешендә импортны алмаштыру мәсьәләсендә фикер алышты.

ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ ЮЛ. Форум кысасында Рөстәм Миңнеханов «ДОМ.РФ» җәмгыяте генераль директоры Виталий Мутко һәм «Россия автомобиль юллары» компаниясе идарәсе рәисе Вячеслав Петушенко белән очрашты. Сөйләшү нәтиҗәсе буларак ике килешү имзаланды: Татарстан Хөкүмәте һәм «ДОМ.РФ» арасында фәнни-техник һәм «Автодор», Татарстан һәм «ДОМ.РФ» арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүләр.

ТӘҮГЕ ТАПКЫР

Казан 2024 елда моңарчы күрелмәгән халыкара спорт ярышын кабул итәчәк. Бу хакта Санкт-Петербургта узган икътисади форумда игълан иттеләр. «Киләчәк Уеннары – 2024»не оештыру буенча килешүне Россиянең спорт министры Олег Матыцин һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов имзалады.

«Киләчәк Уеннары» – гадәти һәм цифрлы спорт ярышларын берләштергән зур чара. Катнашучылар теге яки бу ил һәм җирлек данын яклап түгел, ә аерым клубларга берләшеп чыгыш ясый. «Киләчәк Уеннары»н оештыру нияте турында былтыр Казанда узган «Россия – спорт державасы» форумында игълан иткәннәр иде. Быелгы вакыйгалар аркасында спорт дөньясында килеп чыккан таркалу исә бу эшкә ныклап алынырга мәҗбүр итә. Тәүге ярышны оештыру хокукына 16 төбәк дәгъва кылган иде. Ахырда бу исемлектә Мәскәү, Санкт-Петербург, Калуга, Казан һәм «Сириус» федераль җирлеге калды. Җиңүче итеп Татарстан башкаласын игълан иттеләр. Гаҗәп түгел. Казанда мөмкинлекләр дә, тәҗрибә дә, теләк тә җитәрлек. Бу – Россия Хөкүмәте вице-премьеры Дмитрий Чернышенко фикере.

Мөмкинлекләр, тәҗрибә һәм теләк турында «Киләчәк Уеннары – 2024»не оештыру буенча килешүне имзалаганда Президент Рөстәм Миңнеханов та әйтте. «Республикада куәтле IT-инфраструктура булдырылган. «Иннополис» махсус икътисади зонасында 323 инновацион компания эшли. Татарстанда Цифрлаштыру елының мөһим проекты – яңа IT-квартал булдыру. Безнең инновацион юнәлешләр буенча бәйгеләр үткәрү тәҗрибәсе бар», – диде ул һәм тәүге тапкыр узасы Уеннарны яхшы итеп оештыру өчен барысының да эшләнәчәген җиткерде.

Дмитрий Чернышенко фикеренчә, әлеге Уеннарга игътибар, Олимпиада белән чагыштырганда, 7 мәртәбә күбрәк булыр дип фаразлана. «Татарстанның чараларны ничек оештыра белүен барыбыз да беләбез. Нинди зур җаваплылык булачагын аңлыйбыз, өстәвенә вакыт аз, нибары ел ярым гына калды. Уңышлар, хәерле юл телим!» – диде ул.

Ярышлар 9 көн дәвам итәчәк һәм 15 төрдән гыйбарәт булачак. Араларында киберспорт, роботлар бәйгесе, кибатлетика, дроннар ярышы һәм башкалар бар. Уеннар 8 объектта узачак.

Экология

Һава чистара

Узган ел Казан халкыннан һавадагы сасы искә зарланып 300дән артык шикаять килгән. Күбесе Самосырово бистәсендәге полигон янәшәсендә яшәүчеләрдән. Быел бу чүплекне чистарта башлагач, мөрәҗәгатьләр саны кимегән. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков сөйләде.

– Без республика халкыннан килгән шикаятьләр буенча кайсы якта һаваның сыйфаты начар икәнен беләбез. Әлеге чүплек зур проблема булды. Чынлап та, бу бистәдәге истән зарланучылар шактый. Быел чүплекне юкка чыгару эшләре башлангач, зарлар да кимеде. Хәзерге вакытта чүплек пленка белән капланып куелды. Андагы чүптән электр энергиясе алырга җыенабыз, – диде министр.

Әлеге эш «Экология» илкүләм проекты кысасында «Чиста ил» федераль программасы буенча башкарыла. 39,2 тонна чүптән алынган электр энергиясе башкала халкына 20–25 елга җитәчәк. Чүплек элек һавага начар йогынты ясаса, киләчәктә файда китерәчәк.

Министр илкүләм проектлар ярдәмендә һаваны чистару буенча зур эшләр башкарылганын кат-кат әйтте. 2006 елдан бирле һаваның пычрануы 2 тапкыр кимегән. Экологлар һәр зарарлы матдәне җентекләп тикшерәләр, аларның һәркайсыннан анализ алына. Моның өчен республикада атмосфера һавасы пычрануга контроль станцияләре эшли.

– Мондый станцияләр пычрату чыганакларын тиз арада ачыкларга ярдәм итә. Әйтик, Куйбышев сусаклагычында төпкә киткән туксаннан артык көймә бар. Аларның барысын да алдан өйрәндек. Нинди чималдан ясалуын, авырлыгын, аларны ничек итеп судан чыгарып булуы турында мәгълүмат тупладык. Быел без 14 көймәне судан чыгарачакбыз. Август аенда эшкә тотынырбыз дип торабыз, – ди Александр Шадриков. – Тирә-якны чистарту тиз һәм җиңел генә башкарылмый. Һәр нәрсәнең тәртибе бар. Әйтик, шушы көймәләрне кая тапшырырга дигән сорау килеп туа. Юридик якларын да уйларга кирәк.

Министр ЮХИДИ хезмәткәрләре белән берлектә уздырылучы «Саф һава» операциясенә дә тукталды.

Аның нәтиҗәләре буенча машиналардан чыккан һавада зарарлы газлар күләменең кимүе ачыкланган. 1994 елда ул 27,5 процент булса, 2021 елда бу күрсәткеч 2,8 процентны тәшкил иткән.

Экологлар һаваның пычрануын даими рәвештә контрольдә тоталар. Моның өчен 16 автомат станция эшли. Алар елына 4 миллионнан артык тикшерү уздыра.

– Дүрт ел эчендә безнең лабораторияләргә бөтен дөньяда кулланыла торган 90 миллион сумлык җиһаз куелды. Без алар биргән нәтиҗәләргә таянып эшлибез, – ди Александр Шадриков. – Татарстанда һавадагы формальдегидны билгеләү буенча җиһазлар урнаштырылды. 2021 елда әлеге җиһаз Түбән Камадагы күчмә лабораториягә, быел Чаллы һәм Казанда берничә күчмә станциягә урнаштырылды.

Казанда исә ике күчмә лаборатория бар. Бу лабораторияләр формальдегидны билгеләү өчен өстәмә җиһазлар белән тәэмин ителгән. Халыктан килгән зарларны тикшерергә шул җиһазларны алып чыгалар. Шикаятьләр буенча урынга чыккач, 20 минут эчендә һаваның сыйфаты турында әйтеп бирә алалар.

– Татарстанда сәнәгать оешмалары күп. Әлбәттә, алар һаваны пычратмый тормый. Әмма бу оешмалар экологияне саклар өчен дә үзеннән зур өлеш кертә. Соңгы елларда газ белән йөри торган автобуслар артты. «Бөке»ләрне дә киметәсе иде. Тикшерүләр шуны күрсәтә: машиналар «бөке»дә чакта һаваны бик пычраталар, – ди министр. – Һавасы чиста дип, ниндидер районны аерып әйтә алмыйбыз. Бар да үзебездән тора. Әгәр без табигатьне саклауга өлеш кертсәк, чүпләмәсәк, кайда да яшәү өчен уңай шартлар булачак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Авыл эшмәкәрләре

БАЛЫК, КАП... КЫНА ТҮГЕЛ ШУЛ

Зур-зур бассейннарда йөзгән балыкларны күргәнегез бармы? Ә уылдык әзерләүләрен күзәтергә туры килдеме? Безгә боларның барысын да Минзәлә районының Гөлек авылында әтиле-уллы Мөхәммәтҗановларның балыкчылык хуҗалыгында күрергә насыйп булды. Шунда ук әлеге бизнесның бар рәхәте һәм авырлыклары турында да белдек.

Рәшит, Дамир һәм Ринат. Өч бертуган егетләрнең исемен алган «РАДАР» фермер хуҗалыгы иде ул. Безне исә хуҗалыкта аларның әтиләре, шушы эшнең башында торучы Габдрәшит Мөхәммәтҗанов каршы алды.

– Мин – гомер буе инженер-төзүче булып эшләгән кеше, – дип таныштырды ул үзе белән. – 2000 елда Казахстаннан бабаларыбызның кендек каны тамган җирләргә кайтып төпләнергә уйладык. Кайткач, төзелештә эшләдем. Шуннан соң улларым белән уйлаштык та балыкчылык белән шөгыльләнергә булдык. Өч буа алып, шунда балык үрчетә башладык. Карп, сазан, толстолобик, беломор, кәрәкә… Ләкин эшебез без уйлаганча шома гына бармады. Беренчедән, ул буалар балык үрчетү өчен бик үк җайлашмаган иде. Икенчедән, халык балык тотарга йөрде. Мондый шартларда балык үстереп булмавын аңладык. Өченчедән, буаларны арендага алып эшләдек, шунлыктан ышанычлы булмады. Чөнки күпме көч, вакыт һәм акча керткән буабызның берсен законсыз рәвештә тартып алдылар.

Әлеге гаделсезлектән соң Мөхәммәтҗановлар ташландык бинага ремонт ясап, шунда зур-зур бассейннар урнаштырып, аларда мәрсин (осетр) һәм чөгә балыгы үрчетә башлый.

– Бик катлаулы эш. Иң кыены белгечләр булмау иде. Шуңа күрә бүгенге көнебезгә ялгышлар, төзәтүләр аша килдек. Әле дә булса өйрәнәбез. Күбрәк белгән саен сораулар арта гына бара. Шунысы куандыра: бирегә беркем килми, урлашмый, китегез, дип кумый. Алга таба да үз куышыбызда тыныч кына эшләргә ирек бирсеннәр иде.

Цехта 20 куб су сыйдырышлы – биш, 10 куб су сыйдырышлы 3 бассейн урнаштырылган. Һәркайсында төрле авырлыктагы балыклар үрчетелә. Гомумән алганда, барлык бассейннарда берьюлы 4 тонна балык тотарга мөмкин икән. Әлегә цех елына 10 тонна балык үстерә. Балыкчы әйтүенчә, чөгә балыгы – 10–12 килограммга, мәрсин – 80–100 килограммга, кырпы (белуга) – 1,5–2 тоннага кадәр, калуга 600–700 килограммга кадәр үсә. Быел балыкчылар, бездән ярдәм булсын дип, Идел, Камага да балыклар җибәрә башлаганнар. Маймычлар исә янәшә цехтагы ванналарда үрчетелә.

Читтән караганда матур, табышлы бизнес кебек күренсә дә, балыкчылар очраша торган авырлыклар да шактый булып чыкты. Сер бирергә тырышмаса да, авырлыклар барлыгын әледән-әле искәртте Габдрәшит Мөхәммәтҗанов.

– Әлегә безгә бик авыр, чөнки электр бәясе бик нык кыйммәт, – диде ул. – Электр энергиясенең бер киловатты өчен 8 сум түләргә туры килә. Бу – бик зур сумма. Әле сез килер алдыннан гына кайдадыр авария булып, утны сүндерделәр. Өч сәгать утсыз утырдык. Генераторларны эшкә җигеп, балыкларны чак коткарып калдык. Иң куркынычы шул – әгәр су 40 минут хәрәкәтләнмәсә, бөтен балык үлеп бетә. Аларга су чиста булырга, кислород яхшы керергә тиеш.

Балыкчы сүзләренә караганда, әлегә аларны сатып алучылар да аз икән. Шуңа күрә зыянга эшләмәсәләр дә, табыш турында сөйләшергә иртәрәк, ди ул.

– Әлегә халыкта мәрсин семьялыгыннан булган балыкларны куллану культурасы юк. «Аны ничек ашарга соң, ничек әзерләргә?» – дип еш сорыйлар. Кыскасы, кайчандыр Петр I халыкны бәрәңге ашатырга өйрәткән кебек, безгә дә халыкны балык ашарга өйрәтәсе булыр, ахры. Бәлки, ихтыяҗ зур да булыр иде. Тик хәзер халыкның акчасы юклыгы сизелә. Казан рестораннары белән дә сөйләшеп карадык. Ләкин көндәшлек көчле, – ди фермер.

Авырлыклар болар белән генә чикләнми икән. Тиешле ярдәмне ала алмый җәфаланабыз, ди Габдрәшит Мөхәммәтҗанов.

– Кызганыч, сыерлар тоткан кешеләргә ярдәм зуррак. Балык тотучылар белән кызыксынучы, ярдәм кулы сузучы юк. Балыкчылыкта корпорация никадәр зуррак булган саен, субсидияләр дә алу җиңелрәк. Кече оешмаларга бик авыр, шунлыктан күпчелек программаларга керә алмыйбыз, – ди ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шулай да ул күңелен төшереп, кулын селтәп китәргә ашыкмавын әйтте.

– Мин балыкчылык бизнесының киләчәге бар дип саныйм, – дип күңелен юата фермер. – 1980 нче елларда СССРда балыкчылык буенча иң алдынгы технологияләр, көчле заводлар эшли иде. Без фән буенча да барысыннан да алда булдык. Тик 1991 елдан соң безнең иң яхшы белгечләрне башка илләргә алып чыгып бетерделәр. Шулай да эзләнәбез, безнең өчен иң яхшы вакытлар килер дип өметләнәбез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

«МЫЛТЫКТАН БАШКАНЫ БЕЛМӘДЕМ»

Минем әби бабайның дүртенче хатыны булган. Юк, хатыннар яратканга күрә түгел. Мулла да булмаган бабай. Сәбәбе гади: беренче өч хатыны яшьли үлгән. Өйләнеп тә өлгерми, тол калып барган. Бүген бу хакта шаккатып сөйлибез. Ә ул чорда мондый хәлгә исләре китми. Чөнки дөньясы кырыс. Фаҗига арты фаҗига, сугыш, ачлык, юклык...

Илдар Мөхәммәтҗанов

Минем бабай (бу язмада сүз әнинең әтисе турында бара) 1896 елда ук туган. Чыгышы белән Саба районы Олы Шыңар авылыннан. Беренче тапкыр Гражданнар сугышыннан кайткач өйләнә. Ачлыкның котырган чагы. Авыллары белән кырылганнар. Гомәр бабай – ул вакытта 25 яшьлек ир – Мәскәүгә чыгып китә. Эшләп, гаиләсенә аз-маз ипиен, акчасын җибәреп тора. Ләкин яшь хатынын саклап кала алмый. Ире әйләнеп кайтканчы, ул ачлык корбанына әйләнә.

Берәр елдан соң кабат гаилә кора. Бу юлы Гомәр читкә китәргә ашкынмый. Бер авызы пешкәч, ничек тә булса, авылда калырга тырыша. Мал-туар асрап, көн күрергә теләге. Әмма бар нәрсә дә без теләгәнчә түгел шул. Бу юлы да бәхет аны урап уза. Икенче хатынының гомере шулай ук бик кыска булып чыга. Бала тапканда үлә, сабые да исән калмый. Ачлык халыкның җанын да, тәнен дә алҗыткан. Яшәү өчен көрәшергә көч кирәк бит ул. Ә ул дәрт-дәрман каян килсен? Мескен хатынның туасы җанга гомер бүләк итәрлек хәле булмый.

Гомәр кабат ялгыз ир исемен күтәреп, җан асрый башлый. Авылларга беренче техника кайта башлаган вакытлар. Тракторга охшаган машинаны күреп, телсез калалар ул чорда. «Эх, шушы «тимер ат»ны иярләсәң иде ул!» – дип, Гомәр күңел эченнән генә хыялланып яши. Хәтта укырга китәргә теләге була. Авылдан җибәрмиләр. Трактор авылга бер, мең кешене утыртып булмый. Ә эшче куллар гел кирәк, янәсе.

1930 нчы еллар уртасында Гомәр бабай – инде күпне күргән ир – кабат өйләнергә була. Күрше Мәтәскә авылы кызын димлиләр аңа. Бик чая, үткен, тырыш кыз булган. «Күз ачып йомганчы, әти-әнисе янына барып кайта торган иде», – дип искә ала туганнары. Шул чаялыгы харап та иткән инде. Кышкы бураннан да курыкмыйча, юлга чыгып киткән ул. Тик бу юлы кире әйләнеп кайтмаган. Берникадәр вакыттан мәктәп балалары чаңгыда шуганда юлдан ерак түгел өшегән гәүдәсен күреп алалар. Адашып үлгән, мәрхүмә.

Гомәр бабай шуннан соң өйләнү турында инде авызын да ачмый. Хәер, ачып ни файда? Илдә фин сугышы башлана. Инде 40ка җитеп килүче ирне, озак уйлап тормыйча, фронтка җибәрәләр. Бабай шул китүеннән авылга бары тик 10 елдан соң гына әйләнеп кайта. Чөнки фин сугышыннан соң фашистлар белән аяусыз көрәш, японнар белән бәрелеш китә... Кыскасы, гомеренең бик зур өлеше корал күтәреп уза.

Гомәр авылга бик картаеп, таушалып, бетерешеп кайта. Үзе еш әйтә торган булган: «Бу – минем туган авылыма соңгы сулыш алырга кайтуым иде. Шушы туфракта җирләнәсем килде».

Әмма үлем турында сөйләнү иртәрәк булган әле. Ходай башкача хәл иткән. 51 яшендә апалары кыстый-кыстый аны өйләндерә. «Картаймыш көнеңдә бер иптәш булыр», – дип үгетлиләр. Бәдриҗамал – ялгызы ир бала үстерүче тол хатын. Гомәрдән 10 яшькә кечерәк. Ә менә бу еиреннән озынрак булган. Ләкин сугыштан соңгы елларда мондый вак-төяккә кем игътибар иткән? Иң мөһиме – бер-береңә терәк булу.

Шулай бергә картаербыз дип сүз куешкан ике җан берзаман әти-әни булу бәхетенә ирешә. Гомәр бабайның бу беренче баласы бит әле. Кем уйлаган инде шактый олы яшьтәге кешеләрнең бер-бер артлы дүрт баласы туар дип? Дөрес, аларның икесе генә исән кала. Кызлар – Мөнирә һәм Разыя. Шуларның берсе – минем әни. Ул туганда, әтисенә инде 53 яшь булган. «Әти бик карт кеше иде», – дип искә ала ул. Билгеле инде, бүгенге 53 яшьлекләр белән ул чордагы кешеләрне чагыштырырлык түгел. Җиңү көне алдыннан мәктәпкә истәлекләр белән уртаклашырга йөри торган булган. «Әле дә күз алдымда тора: инде таушалып беткән кәчтүменә бер кочак орден-медальләрен тагып елмаеп чыгып китәр иде. Елый-елый кайтып керер иде. «Ни булды сиңа?» – дип сораганга, кул селтәп, аягым авырта, дип җавап бирер иде, дип сөйли әни. Сугышта алган ярасы шулай кузгала торган булган. Аяктагы яра, үз чиратында, күңел ярасын ярсыткандыр, мөгаен. Ул шундый вакытларда гел үкенечле язмышына үпкәләп елый торган булган. «Яшьлегемне сугыш урлады, инде тыныч яшәрмен дип уйлаганда, кабат корал тотып, фронт кырларында йөрдем. Бер юньле-башлы һөнәрем юк. Мылтыктан атудан гайре башка эш белмәдем. Шуңа картлык көнемдә көтүчегә калдым. Юкса Мәскәү хәтле Мәскәүне күргән кеше бит мин! Эх, шунда гына яшәп калган булсам!» – дип сыкрана торган булган. Беркатлы булган инде бабай. Анда калган булса, бәлки, аны башка язмыш көтәр иде? Күпме михнәт күреп тә, 70 яшькә җитә алуын, соң булса да, әти булуын Ходай бүләге дип кабул итәргә кирәк. Ләкин без моны бүген аңлыйбыз. Ә ул чор кешеләре үзләрен бер көнгә булса да бәхетле хис итә алдылар микән? Юктыр, мөгаен. Чөнки дөнья аларны, камчысын жәлләмичә, бик каты кыйнаган. Үлгәнче, шушы яралары сыкрап, кан саркып торган.

Люция НОТФУЛЛИНА

ВЛАДИМИР ВАВИЛОВ:

«Күктән күрәләр кебек»

Казанда эшләячәк икенче хосписны төзү эшләре әкренләп ахырына таба якынлашып килә. Бинаны төзеп куйганнар инде. Әле эчке эшләр белән беррәттән, су кертәсе, канализация ясыйсы, җылылык казаны куясы бар. Бу хакта бүген журналистларга Анжела Вавилова фонды рәисе Владимир Вавилов сөйләде.

Бина әзер булса да, эшләнәсе эше күп әле. Эчке яктан ремонт ясарга кирәк. Шунысы сөендерә: яңа хосписның үз котельные бар. Ул иң аскы катта урнашкан. Кыскасы, анда яшәүчеләргә салкын булса, җылылыкны ачып куячаклар, эссе икән, сүндереп була. Шулай ук кайнар сулары да ел әйләнәсе бетеп тормаячак. Без килгәндә, бер төркем эшчеләр канализация торбасын урнаштыралар иде. Бу эш беткәч, хосписның икенче ягыннан су торбасын салачаклар.

– Бар да акчадан тора. Ул бар икән, төзелеш дәвам итә. Кайчакта инде нишлим, каян акча табыйм икән, дип тә аптырап калам. Кулымнан эш төшкән чаклар да була. Тик шул чакта ярдәм килә. Күктән күрәләр кебек. Уйламаган җирдән мәрхәмәтле кеше килеп чыгып, миллионнар күчереп куя. Әле ул үзенең исемен атамауны да сорый, – ди Владимир Вавилов. – Дөрес, хоспис төзелешенә республика халкы да ярдәм итә. Кемдер 50, 100, 1000 сум сала. Аларга да рәхмәт. Әмма хәзерге бәяләрне уйлап шаккатарлык. Канализация ясауга 20 миллион сум акча тоттык.

Владимир Вавилов хосписның соңгы катында авыруларны соңгы юлга озату залы булыр дип планлаштыра. Инде ул бүлмәне тәртипләп, җиһазлар куеп бирүче оешма да табылган. Аны христиан динендәгеләргә дә, мөселманнарга да туры китереп ясаячаклар.

Икенче катта озак вакыт дәваланучы кешеләр ятачак. Республикада соңгы көннен хосписта уздырырга теләүчеләр күп икән. «Көн саен ярдәм сорап шалтыратучылар бар», – ди Владимир Вавилов. Тик аларның бөтенесенә дә булыша алмыйлар шул. Татарстанда 20 мең кешегә «яман шеш» диагнозы куелган. Әле алар янәшәсендә картлык чирләре, нерв авырулары белән интегүчеләр бар. Әнә шуңа да бу хосписны тизрәк төзеп бетерәселәре килә. Владимир Вавилов: «Әгәр миннән генә торса, Анжела Вавилова фондының 20 еллыгына, киләсе елның март аена эшне тәмамлар идем», – ди. Тик бар да акчага килеп төртелә.

– Беренче хоспис 22 кешелек. Монысында әлегә 60 урын булыр дип торабыз. Әмма безнең мөмкинлекләр күп. Бер палатага 4–5 карават куйган очракта, хоспис 200 кешене сыйдыра ала. Тагын шунысы да бар: монда беркайчан да ут та, су да, җылылык та бетмәячәк, – ди Владимир Вавилов.

Җитәкче хоспис төзелешенә генә түгел, анда ятучы авыруларга ярдәм күрсәткән һәркемгә, оешмаларга рәхмәтле. Быел кыш көне, кар күп булу сәбәпле, бер авылга яман шеш белән интегүче кеше янына керә алмаганнар. Аны Казанга алып китү өчен, башка төр машина кирәк булган. «Татнефть» оешмасы аларга машина биргән.

– Хосписта нинди авырулар яшәгәнен бик күпләр аңлый башлады инде. Шуңа да кешеләр ничек тә ярдәм итәргә тырыша. Якыннары мәкерле чир белән очрашкан кешеләр елый-елый рәхмәт әйтә. Авырулар үзләре дә актык көннәрен, сәгатьләрен бар авыруларын онытырып яшәткән өчен рәхмәт укый. Иң зур сүзләр шул инде, – ди Владимир Вавилов.

Ә мин исә, аны күргән саен, күңеленә сокланып кайтам. Булса да булыр икән изге җан! Матур уйлар, хыяллар белән яши ул. Барысы да авырулар өчен бит. Теләге – яман чир белән көрәшүчеләр сыкранмый, сызланмый яшәп калсын. Ә ул кулдан килгәнне эшли. Төзелеш барышын үзе күзәтә. Белмәгәнен белгечләрдән сорый. Казандагысын чит ил хосписларыннан да яхшырак булсын дип тырыша. Күңел, йөрәк турында да онытмый. Хоспис бакчасына алмагачлар, матур чәчәк ата торган куаклар утыртырга хыяллана.

Теләге булган һәркем хоспис төзелешен тизләтә ала. Моның өчен www.angela-vavilova.ru сайтына кереп, үз ярдәмеңне калдырырга кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз икенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз икенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. О.В. Коробченконы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры итеп билгеләп куюны килештерү турында.
3. Коробченко Олег Владимировичның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты составына һәм Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында.
5. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Чуаш Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 11 маендагы 13 номерлы килешүне раслау хакында.
6. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Башкортстан Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 31 маендагы 17 номерлы килешүне раслау хакында.
7. «2021 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 298-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «2021 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 299-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 308-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
10. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 305-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. 2021 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап.
12. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 286-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
13. «Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләр турында» 266-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
14. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 307-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 306-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
16. «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 301-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 295-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 296-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
19. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 300-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
20. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 303-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
21. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.
22. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 304-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
23. «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 297-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
24. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 64 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы хакында.
25. «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы турында.
26. «Георгий тасмасы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 109180-8 номерлы федераль закон проекты турында (Георгий тасмасының статусын билгеләү хакында).
27. «Дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 119762-8 номерлы федераль закон проекты турында (сатып алуны бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, башкаручыдан) гамәлгә ашыру өлешендә).
28. «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 115273-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт сәнәгатьне үстерү фондлары тарафыннан кредит оешмаларында счетлар ачу мөмкинлеге хакында).
29. «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» Федераль законның 5 статьясындагы 1 өлешенең 3.1 – 3.5 пунктларының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 104089-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең маркировкалау өлкәсендәге вәкаләтләрен туктатып тору өлешендә).
30. «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 121564-8 номерлы федераль закон проекты турында.
31. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.3 һәм 23.79 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 106447-8 номерлы федераль закон проекты турында (федераль әһәмияттәге Севастополь шәһәре башкарма хакимияте органнарының административ хокук бозулар турындагы аерым эшләрне карау вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә).
32. «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» Федераль законның 11 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 76992-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашуына кагылышлы аерым юридик-лингвистик һәм мәгънәви төгәлсезлекләрне бетерү өлешендә).
33. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның 29 статьясына үзгәреш кертү хакында» 127048-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби хезмәткәрләрнең һәм махсус хезмәт үтүче затларның физик әзерлеген оештыру тәртибен камилләштерү өлешендә).
34. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 18 һәм 19 статьяларына һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 78 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 101105-8 номерлы федераль закон проекты турында (автомобиль юлларын төзү максатларында гомумтаралган файдалы казылмаларны эшкәртүнең алдан хәбәр итеү тәртибен кертү өлешендә).
35. «Россия Федерациясе Торак кодексының 169 һәм 171 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 122372-8 номерлы федераль закон проекты хакында (капиталь ремонтка кертем түләүгә чыгымнарга компенсация бирү өлешендә).
36. «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 130228-8 номерлы федераль закон проекты турында (кайнар суга беркомпонентлы яисә икекомпонентлы тарифлар билгеләү өлешендә).
37. «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 29[1] статьясына үзгәрешләр кертү турында» 135975-8 номерлы федераль закон проекты хакында (гадәттән тыш хәлләр яисә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү буенча чаралар күрү шартларында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын үзгәртү хакында).
38. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55[16] статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Смоленск өлкә Думасы закон чыгару инициативасы хакында.
39. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 15 июне, № 1455-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп өч елга түбәндәгеләрне сайларга:
Татарстан Республикасы Мамадыш суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Гатауллин Рөстәм Рәшит улын;
Татарстан Республикасы Түбән Кама суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Кокуйский Андрей Владимировичны;
Татарстан Республикасы Түбән Кама суд районы буенча:
12 нче суд участогына – Казакова Гөлнара Миңнегали кызын.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп чикләнмәгән вакытка түбәндәгеләрне сайларга:
Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров суд районы буенча:
6 нчы суд участогына – Бейзер Алла Александровнаны;
Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Мәскәү суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Гыйлаҗев Руслан Хәлил улын.

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә сайланган Бейзер Алла Александровнаның Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вәкаләтләре чоры 2022 елның 1 июленнән башлана.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 15 июне, № 1456-VI ДС

О.В. Коробченконы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры итеп билгеләп куюны килештерү турында

О.В. Коробченконы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры итеп билгеләп кую турында Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 18 һәм 49 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Коробченко Олег Владимировичны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры итеп билгеләп кую белән килешергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 15 июне, № 1457-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Массакүләм коммуникацияләрне һәм мәгълүмати технологияләрне үстерүгә зур өлеш кертүе, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Исәпләү системалары фәнни-җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең бүлек мөдире **Грот** Виктор Александрович **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Дуслык ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Килеп туган гадәттән тыш шартларда кешеләрне үлемнән коткарудагы фидакарьлеге, батырлыгы һәм кыюлыгы өчен «Татарстан Республикасы янгын сагы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең Чаллы янгынга каршы хезмәте отряды Тукай муниципаль районы Бикләң авылының янгынга каршы сак хезмәте аерым посты җитәкчесе **Фәрдиев** Рамил Рәис улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Янгындагы батырлык өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Республика клиник неврология үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табиб-неврологы **Бабичева** Наталья Николаевнага, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең психотерапия һәм наркология кафедрасы доценты **Белоусова** Марина Владимировнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы нейрохирургия бүлекчәсе мөдире – табиб-нейрохирургы **Игнатьев** Валерий Георгиевичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 4 номерлы реанимация һәм интенсив терапия бүлекчәсе экспресс диагностика лабораториясе мөдире – клиник лаборатория диагностикасы табибы **Исламгалиева** Фәридә Мәннаф кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар диспансер-поликлиника бүлекчәсе участок балалар табиб-психиатры **Кувина** Елена Владимировнага, «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хатын-кызлар консультациясе табибы – акушер-гинекологы **Морзина** Гөлчирә Яриәхмәт кызына, Казан шәһәренең «Профессор К.Ш. Зыятдинов исемендәге 18 номерлы үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының оештыру-методика эше буенча урынбасары **Садриева** Лилия Нәүфәл кызына, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең травматология бүлекчәсе мөдире – табибы – травматолог-ортопеды **Сизинцев** Виктор Владимировичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең нефрология бүлекчәсе мөдире – табиб-нефрологы **Фәхретдинова** Ольга Юрьевнага, «2 номерлы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе стационарының хирургия бүлекчәсе мөдире – табиб-хирургы (Чаллы шәһәре) **Хәлилов** Рафикъ Ирфан улына, «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кардиохирургия бүлекчәсе табибы – йөрәк-кан тамырлары хирургы **Габделҗанов** Илдар Васыйл улына, «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасы мөдире – поликлиниканың функциональ диагностика табибы **Гаязова** Энҗе Шамил кызына, «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кан тамырлары хирургиясе бүлекчәсе табибы – йөрәк-кан тамырлары хирургы **Садыйков** Рөстәм Фиркать улына, «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе Соколка табиблык амбулаториясенең гомуми практика табибы **Сәләхетдинов** Ришат Гайфи улына, Казан шәһәренең «11 номерлы шәһәр балалар поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы педиатрия бүлекчәсе мөдире – табиб-педиатры **Тимашева** Венера Мансур кызына, Казан шәһәренең «2 номерлы клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Фәйзуллина** Регина Наил кызына, «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең эпидемиология бүлекчәсе мөдире – табиб-эпидемиологы **Шәрәфетдинова** Валентина Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш миендә кан әйләнеше кискен бозылган авырулар өчен интенсив терапия һәм реанимация блогы булган неврология бүлекчәсенең дәвалау физкультурасы буенча инструкторы **Галимова** Рузалия Котдус кызына, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең оператив бүлеге шәфкать туташы **Заялова** Раиса Галимзян кызына, «Перинаталь үзәкле шәһәр балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасының 3 педиатрия бүлекчәсе өлкән шәфкать туташы (Түбән Кама шәһәре) **Кәлимуллина** Зулифа Мисхат кызына, «Саба үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең теш техникы **Кәримова** Фалия Хөснулла кызына, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең җәмәгать сәламәтлеге, икътисад һәм сәламәтлек саклауга идарә кафедрасы доценты **Прокопьев** Валерий Петровичка **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«СтройТехЛидер» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе **Ильин** Владимир Александровичка, «КАМАтранссервис» транспорт-экспедиция фирмасы» акционерлык җәмгыятенең Түбән Кама шәһәре механикалаштырылган колоннасы автомобиль йөртүчесе **Кудрявцев** Владимир Михайловичка, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең автомобиль йөртүчесе **Мельников** Игорь Петровичка, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автотранспорт хезмәте автомобиль йөртүчесе **Ткачев** Александр Ивановичка, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең эксплуатация бүлеге автомобиль йөртүчесе **Хәбибуллин** Марат Таһир улына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ КАРАРЫ

гражданин Ч.В. Мәҗитов шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацының, 2.1 пунктының һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча

Казан шәһәре 2022 елның 27 мае

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып, ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацының, 2.1 пунктының һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин Ч.В. Мәҗитов шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Г.Л. Удачина мәгълүматын, яклар – гражданин Ч.В. Мәҗитов, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган органнар вәкилләре – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең социаль законнар бүлеге мөдире Д.И. Мәхмүтов, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге әйдәүче консультанты Р.Җ. Асьмаева аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Ч.В. Мәҗитов Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының (алга таба шулай ук – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары) 2 пункты белән, әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба шулай ук – Нигезләмә) 9.11 пункты белән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның (алга таба шулай ук – 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта) «а» пункты белән аларның үзара бәйләнешендә үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Әлеге эш буенча тыңлаулар барышында мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары бозылуын күрсәтеп, шулай ук әлеге карарның 2.1 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану үтенече белән тулыландырып, үз таләпләрен төгәлләштерде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының шикаять белдерелә торган 2 пунктындагы икенче абзацында түбәндәгеләр билгеләнгән: пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнар белән күздә тотылган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарга, мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» – «г», «е», «ж» пунктлары белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү бирелә, 2019 елда аның күләме 486 сум тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2.1 пунктында әлеге карарның 2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда күрсәтелгән ялгыз яшәүче гражданнарның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләгәндә 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктчасы нигезендә 40 квадрат метр урынына 80 квадрат метр кулланыла дип каралган.

Нигезләмәнең 9.11 пункты нигезендә пенсионер үз милкендәге торак урынында торак урын милектәшләре булган һәм торак урын милектәшләре булмаган гаилә әгъзалары белән бергә яшәгәндә аңа транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү пенсионерга караган торак урын мәйданының күләме 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктында яки «б» пунктында гаилә әгъзасы өчен билгеләп күрсәтелгән мәйданның иң чик күләменнән артып китмәү шарты белән билгеләнә.

63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты нигезендә гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе дигәндә гаилә әгъзаларының (гражданның) милкендә мәйданы гаиләнең һәрбер әгъзасына исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артыграк туры килә торган торак урын (торак урынның өлеше) булу аңлашыла.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Ч.В. Мәҗитов 2019 елның ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алучы булып торган. Әлеге түләү туктатылу сәбәпле ул Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына аңлатмалар сорап мөрәҗәгать иткән, аннан алынган җавап буенча 2019 елның 1 апреленнән үз көченә кергән 542 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр нигезендә аңа транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тартылган. Кертелгән үзгәрешләр нигезендә пенсионерга, әгәр аның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе милек хокукындагы торак урыны 40 квадрат метрдан артмаган булса, транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләнә. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, әлеге үзгәрешләр 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты нормаларына сылтама ясый, ул пенсионерларга социаль ярдәм чараларын бирүне регламентлаштырмый, бу исә, үз чиратында, аларга айлык акчалата түләү билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсен куллану мөмкинлегендә билгесезлек тудыра. Моннан тыш, кертелгән «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсе мондый тәэмин ителешне бәяләү барлык гаилә әгъзаларын да исәпкә алып башкарылуын күздә тота. Шуның белән бергә, Нигезләмәнең 9.11 пункты нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында карар кабул иткәндә пенсионерның гаилә әгъзалары исәпкә алынмый. Гражданин Ч.В. Мәҗитов саналганча, болар барысы да әлеге түләүне билгеләгәндә пенсионерның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләү ни рәвешле башкарылуы турындагы мәсьәләдә билгесезлек тудыра.

Моннан тыш, ул югарыда аталган үзгәрешләр «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 7 мартындагы 163 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кертелгән иде, ул 5 пункт нигезендә 2019 елның 1 апрелендә үз көченә керде, дип билгеләп үтә. Мөрәҗәгать итүче санаганча, кертелгән үзгәрешләр аңа карата һәм 2019 елның 1 апреленә кадәр пенсиягә чыккан башка пенсионерларга карата кулланылмаска тиеш, башкача булуы законның кире көче турындагы кагыйдәгә каршы килер иде.

Шулай ук гражданин Ч.В. Мәҗитов Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2.1 пунктында ялгыз яшәүче гражданнарның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпләү механизмы билгеләнгән, аның нигезендә мондый гражданга 40 квадрат метр торак урыны түгел, ә 80 квадрат метр кулланылуына игътибар итә. Мөрәҗәгать итүче мондый алымны гаделсез һәм гаилә әгъзалары булган пенсионерларны һәм ялгыз пенсионерларны тигезсез хәлгә куя торган дип саный һәм пенсионер яши торган торак урын гаиләнең барлык әгъзаларына бүленмәсә, мондый аерма да булырга тиеш түгел дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Ч.В. Мәҗитов Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацын, 2.1 пунктын һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктын «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты белән аларның үзара бәйләнешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы – сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; гаилә, ана булу, ата булу, балачак һәм картлык дәүләт яклавында; һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

1.1. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда тәгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса, Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була дип билгеләнгән.

Әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция суды утырышы барышында 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты нигезләмәләре гражданин Ч.В. Мәҗитовка карата кулланылган яисә кулланылырга тиеш булуы расланмады, чөнки бу нигезләмәләр балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибенә кагыла һәм турыдан-туры пенсионерларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибенә кагылмый.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 63 статьясы нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, утырыш барышында мөрәҗәгатьне карауга алудан баш тартуга нигезләр ачыкланса, шуларның берсе – аның мөмкин булу критерийларына туры килмәве ачыкланган очракларда эш алып баруны туктата.

Димәк, әлеге эш буенча 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты нигезләмәсенең конституциячеллеген тикшерү өлешендә эш туктатылырга тиеш, чөнки мөрәҗәгать итүченең бу өлештә мөрәҗәгате мөмкин түгел.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә бүтән органнар компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацының, 2.1 пунктының һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре алар пенсионерларга, шулай ук алар арасыннан ялгыз яшәүче гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләгәндә мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпләү механизмын билгеләгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Нигезләмәләренә карата гражданин Ч.В. Мәҗитов шикаять белдерә торган 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарны кабул итү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәлә элегрәк Татарстан Республикасы Конституция судының тикшерү предметы булган иде, ул, күрсәтелгән норматив хокукый актны кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Конституциясендә, шулай ук федераль һәм республика законнарында каралган үз вәкаләтләре чикләрендә эш иткән дигән нәтиҗәгә килгән иде (2012 елның 4 июлендәге 49-П номерлы һәм 2013 елның 27 мартындагы 52-П номерлы карарлар). Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән карарлары һәм аларда чагылдырылган хокукый позицияләр үз көчләрен саклый.

3. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясындагы беренче өлешенең «ж» пункты нигезендә социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый. Федераль закон белән Россия Федерациясендә чыгарылган башка акт арасында каршылык булганда, федераль закон гамәлдә була. (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясындагы 2 һәм 5 өлешләр).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законда каралганча, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел. Вәкаләтләрне әлеге статьяда каралган финанслау Россия Федерациясе субъекты бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла һәм федераль бюджеттан өстәмә акчалар бүлеп бирелү өчен нигез булып тормый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясы (беренче өлеш) белән үзара бәйләнештә 13 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы – сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт, һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә. Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясындагы беренче өлеше буенча социаль тәэминат Татарстан Республикасы законында билгеләнгән очракларда һәм күләмнәрдә социаль ярдәм чараларын бирүне үз эченә ала. Мәгънәсе буенча шундый ук гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7 һәм 39 (беренче өлеш) статьяларында билгеләнгән.

Китерелгән конституциячел нигезләмәләрдән закон чыгаручының яше, сәламәтлеге яисә башка үзләреннән бәйле булмаган сәбәпләр аркасында эшли алмаучылар өчен үз хокукларын гамәлгә ашыруда тиешле шартлар булдыруны һәм гражданнарның аеруча киеренке категориясенә ярдәм итүне тәэмин итәрлек социаль яклау системасын урнаштыру бурычы килеп чыга. Шул ук вакытта пенсионерларның матди тәэмин ителеш дәрәҗәсе алына торган пенсия суммасына гына түгел, ә социаль хезмәт күрсәтүләргә һәм төрле ташламалар булуга да бәйле.

Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе нигезендә Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысы, аңа социаль яклау өлкәсендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, киң дискрециягә ия һәм үз акчалары исәбеннән социаль ярдәм күрсәтүнең (булышуның) формасын, төрләрен һәм шартларын, шул исәптән адреслылык принцибын исәпкә алып һәм мохтаҗлыкны бәяләү нигезендә билгеләргә дә, шулай ук күрсәтелгән өлкәдә хокукый җайга салуны үзгәртергә дә хокуклы (2018 елның 27 мартындагы 13-П номерлы Карар).

3.1. Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба шулай ук – 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) Татарстан Республикасында гражданнарның адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган категорияләрен, шулай ук мондый ярдәмнең конкрет күләмнәрен һәм рәвешләрен билгеләгән. Социаль ярдәм чараларын алуга дәгъва итүче гражданнарның ихтыяҗларын тикшерү процедураларын камилләштерү һәм ярдәм бирүгә адреслы якын килүне арттыру максатларында закон чыгаручы югарыда аталган Законга кушымтада мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләү критерийларын раслаган.

Күрсәтелгән Законның 2 статьясындагы икенче өлеше нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә, шул исәптән пенсионерларга социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге норма нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнар белән күздә тотылган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарга, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү бирелә дип билгеләнгән.

Үзенең хокукый табигате буенча күрсәтелгән карарда билгеләнгән хокукый җайга салу билгеләнеше федераль законнар нормаларына нигезләнгән социаль ярдәм чаралары исәбенә керми, ә тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган, билгеләнеше аерым категория гражданнарның матди иминлеген тәэмин итү булган максатчан характерга ия һәм гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чарасы булып тора, аны билгеләү – Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы. Бу аны бирү нигезләре һәм шартлары, социаль-икътисади үсешнең әлеге этабындагы финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, гражданнарның адреслылык һәм бәяләү принципларында республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының шикаять белдерелә торган 2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү, аерым алганда, пенсионерларга аларның уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» – «г», «е», «ж» пунктлары белән билгеләнгән мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган очракта билгеләнә. Күрсәтелгән кушымтаның «а» пункты нигезендә мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе дигәндә гаилә әгъзалары (граждан) милкендәге мәйданы гаиләнең һәрбер әгъзасына исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артыграк туры килә торган торак урын (торак урынның өлеше) булу аңлашыла.

Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү тәртибе Нигезләмәнең 9 бүлеге белән җайга салынган, ул түбәндәге эзлекле этапларны күздә тота: граждан тарафыннан Республика матди ярдәм күрсәтү (компенсация түләүләре) үзәгенә (алга таба – Үзәк бүлеге) әлеге түләүне билгеләү турында тиешле документларны кушып гариза бирелә (9.1 пункт); Үзәк бүлеге тарафыннан вәкаләтле оешмалардан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында карала торган түләүне билгеләү өчен кирәкле мәгълүматлар алу (9.2 пункт); транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү яисә аны билгеләүдән баш тарту турында Үзәк бүлеге тарафыннан карар кабул итү; кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү (9.4 пункт).

Китерелгән хокукый җайга салудан күренгәнчә, гариза бирү этабында да, ведомствоара хезмәттәшлек этабында да мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән мөлкәт цензына туры килү-килмәве турында мәгълүмат җыю процессы бара. Шулай итеп, Нигезләмәнең 9.1 пункты нигезендә граждан транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризага күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документлар күчермәләрен кушып бирә (алтынчы абзац). Нигезләмәнең 9.2 пункты нигезендә Үзәк бүлеге вәкаләтле оешмалардан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында күчемсез мөлкәт булу турында (өченче абзац) билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында мәгълүмат ала (бишенче абзац).

Аталган норматив нигезләмәләрне анализлау Үзәк бүлегенең транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү кысаларында үткәрелә торган гражданның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләү эшчәнлеге турында сөйли. Шул ук вакытта Нигезләмәнең шикаять белдерелә торган 9.11 пунктының сүзгә-сүз эчтәлегеннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүчегә милек хокукында булган һәм аның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен ачыклаганда исәпкә алынырга тиешле торак мәйданын билгеләгәндә, аның белән әлеге торак мәйданында бу торак урын милектәшләре булмаган гаилә әгъзаларының яшәү факты исәпкә алынмый.

Нигезләмәнең 9.4 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм ведомствоара хезмәттәшлек системасы буенча алынган күрсәтелгән документлар, шулай ук граждан алган керемнәр турында белешмәләр (9.1 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацлары, 9.2 пунктның икенче һәм җиденче абзацлары), транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булу турында мәгълүматлар (9.2 пунктның дүртенче абзацы), Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булмау турында (9.2 пунктның алтынчы абзацы) нигезендә Үзәк бүлеге тарафыннан транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү йә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Нигезләмәнең шул ук пункты белән транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр каралган. Мондый карар мөрәҗәгать итүченең мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча мөлкәт цензын арттыру – милектә 40 квадрат метрдан артык торак урыны булу сәбәпле кабул ителергә мөмкин (9.4 пунктның җиденче абзацы). Тиешле исәп-хисап Нигезләмәнең 9.1, 9.2 һәм 9.11 пунктлары белән билгеләнгән хокукый җайга салу кысаларында башкарыла һәм мөрәҗәгать итүченең мөлкәт белән тәэмин ителешен Үзәк бүлеге тарафыннан бәяләүнең нәтиҗәсе булып тора.

Шул рәвешле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацының һәм Нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре, аларның турыдан-туры эчтәлегеннән һәм хокукый мәгънәсеннән чыгып, транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен пенсионерның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча мөлкәт цензына – торак урынының 40 квадрат метрдан да артмаска тиешлегенә туры килүе хокук бирүче шарт булуын билгели. Шул ук вакытта китерелгән нигезләмәләрнең системалы анализы шуны күрсәтә: гражданга транспортта йөрү өчен айлык акчалата түләү билгеләү максатларында, аның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпләү кысаларында исәпкә алынырга тиешле торак урынын билгеләгәндә тиешле торак урынына милек хокукы гына карала. Димәк, башка затларның исәпкә алынучы торак урынына карата хокуклары каралмый, ягъни мөрәҗәгать итүченең торак урынында үзенең әлеге торак урынының милекчеләре булмаган гаилә әгъзалары белән яшәү факты исәпкә алынмый һәм аның мөлкәт белән тәэмин ителешен бәяләү нәтиҗәсенә йогынты ясый алмый, чөнки транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү персональләштерелгән (индивидуаль) характерга ия.

63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктына сылтаманы үз эченә алган 542 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацы нигезләмәләренең юридик конструкциясеннән күренгәнчә, әлеге карарның 2 пунктындагы икенче абзацының һәм Нигезләмәнең 9.11 пунктының хокукый мәгънәсе буенча транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү рәвешендәге социаль ярдәм чарасы үзе мөрәҗәгать итүченең шәхесе белән аерылгысыз бәйле булганга күрә ярдәм күрсәтү турыдан-туры гражданның (пенсионерның) керемнәренә һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә бәйле. Мондый конструкция асылда «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсенең эчтәлеген тәшкил итүче аерым норматив-хокукый характеристикаларны алу ысулы булып тора. Әлеге техниканы куллану гражданнарга социаль гарантияләр бирүдә югарыда китерелгән хокукый җайга салуның нигезен тәшкил итүче төшенчә аппаратының һәм принциплар бергәлегенең бердәмлеген тәэмин итү максатын күздә тота. Карала торган сылтама пенсионерның милкендә Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле торак урын (торак урынның өлеше) булу өлешендә «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсе алынма булудан башка берни дә түгел. Мондый алынма үзеннән-үзе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, булган дискрецион вәкаләтләр нигезендә җайга салынулы хокукый мөнәсәбәтләр үзенчәлекләреннән чыгып, шул ук вакытта мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе формулировкасының мәгънәле әһәмиятен саклап калып, «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсен үз эчтәлеге белән тулыландырырга хокуклы булуы белән бәйле.

Мондый нәтиҗә 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты үзеннән-үзе әлеге Законның 8 статьясындагы 7 өлешен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән, анда 18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын билгели торган, әлеге статьяда турыдан-туры каралганча, ярдәм күрсәтү шул исәптән гаиләнең һәр әгъзасына караган мөлкәттән чыгып исәпләнгән мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә бәйле һәм әлеге нигезләмәне социаль ярдәм чаралары күрсәтүнең башка очракларына карата куллану аталган Закон белән җайга салынмавына да тәңгәл килә. Аерым алганда, анда әлеге Законга кушымтаның «а» пункты нигезләмәләрен пенсионерлар кебек гражданнар категориясенә карата куллануга турыдан-туры күрсәтмә юк.

Шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүченең мондый төрдәге сылтама булу 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктында беркетелгән «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсенең эчтәлегеннән тайпылу мөмкинлегенә юл куймый дигән дәлилләре расланмый.

Китерелгән хокукый җайга салу белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2.1 пункты аерылгысыз бәйле, ул әлеге карарның 2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән ялгыз яшәүче гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләнгән очракта аларның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләгәндә 40 квадрат метр урынына 80 квадрат метр кулланылуын күздә тота. Барлык пенсионерлардан ялгыз яшәүчеләрне аерып күрсәтү үзе үк мондый гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү мәсьәләсен хәл иткәндә, алар белән бергә яшәүче гаилә әгъзасы тарафыннан алар исәп тота алырлык матди ярдәм булмау аерым әһәмияткә ия дигәнне аңлата. Башка сүзләр белән әйткәндә, бу мәсьәләдә гражданның гаилә әгъзалары белән бергә яшәү яки яшәмәү шартларын бәяләү урынлы. Күрсәтелгәннәр гражданның матди хәле турында күзаллауны формалаштыруга карый. Шул ук вакытта гаиләнең бергә яшәүче әгъзасы тарафыннан тиешле ярдәм булмау, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты позициясеннән килеп чыга торган логика буенча, ялгыз яшәүче гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү булмауны тулыландыруның бер чарасы буларак шарт итеп куя. Әлеге искәрмәне күздә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ялгыз яшәүче гражданнар пенсионерларның аеруча киеренке категориясе булуыннан һәм аерым ярдәмгә мохтаҗ булуыннан чыгып эш иткән. Мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча мөлкәт цензын 80 квадрат метрга кадәр арттырып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты андый гражданнар өчен шуның белән транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алуга дәгъва итәргә мөмкинлек бирә торган өстенлек билгеләгән.

Бу Россия Федерациясе Конституция Суды позициясенә тулысынча туры килә, анда билгеләнгәнчә, законнарның мәгънәсен, эчтәлеген һәм кулланылышын, закон чыгару һәм башкарма хакимиятнең, җирле үзидарәнең эшчәнлеген билгели һәм гадел хөкем белән тәэмин ителә торган социаль дәүләтнең, барыннан да элек, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга бурычлы гуманистик башлангычларыннан чыгып (Россия Федерациясе Конституциясенең 2 һәм 18 статьялары), закон чыгаручы гражданнарның аеруча киеренке категорияләренә, матди ярдәмне дә кертеп, дәүләт һәм җәмгыять ягыннан ярдәм алырга мөмкинлек бирерлек һәм шәхеснең дәүләт тарафыннан саклана торган абруен киметми торган (Россия Федерациясе Конституциясенең 21 статьясының беренче өлеше), яше, сәламәтлеге һәм башка үзеннән бәйле булмаган сәбәпләр аркасында эшли алмаучылар өчен үз хокукларын тормышка ашыруда уңайлы шартлар булдыруны тәэмин итәрлек шундый социаль яклау системасын булдырырга бурычлы (2013 елның 14 маендагы 9-П номерлы Карар).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2.1 пунктында билгеләнгән хокукый җайга салу аның дискрецион вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән, үзенең хокукый табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча пенсионерлар арасыннан аеруча киеренке категориягә керүче гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклауның өстәмә гарантияләрен (нигезләнгән өстенлекләрен) билгеләүгә, гавами-хокукый һәм хосусый-хокукый мәнфәгатьләр балансын тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм үзеннән-үзе кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге нәтиҗәгә килә: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацының, 2.1 пунктының һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре алар пенсионерларга, шулай ук алар арасыннан ялгыз яшәүче гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләгәндә мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпләү механизмын билгеләгән дәрәҗәдә гражданнарның, шул исәптән гражданин Ч.В. Мәҗитовның да конституциячел хокукларын юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

Шуның белән бергә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять бирелә торган хокукый җайга салуга гражданнарны ялгыз яшәүчеләр категориясенә кертү критерийларын төгәлләштерә торган, шул исәптән әлеге хәлне раслау өчен пенсионерга нинди документлар тапшырырга кирәк булуын билгеләүче үзгәрешләр кертүгә комачауламый, чөнки әлеге эштә карала торган транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү тәртибе гражданны ялгыз яшәүче категориясенә кертүне ачык һәм төгәл итеп билгеләү механизмы нормаларда каралмаган. Мондый хокукый җайга салу социаль хокукый дәүләтнең асылына, шул исәптән гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын саклап калуның конституциячел принципларына җавап бирер иде.

3.2. Мөрәҗәгать итүченең дәгъва белдерелә торган нормаларга закон кире көчкә ия булмый дигән гомумхокукый принципны куллану турындагы дәлилләренә карата Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

Нигезләмәнең 9.5 пункты нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү барлык кирәкле документлары белән гариза бирелгән айдан башлап билгеләнә һәм билгеләнгән айдан башлап алты ай дәвамында түләнә (беренче абзац). Аталган пунктның дүртенче абзацы нигезендә Үзәк бүлегендә пенсионерның транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү хокукын раслаучы мәгълүматлар булган очракта транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү аңа яңа срокка автомат рәвештә, аның мөрәҗәгатеннән башка билгеләнә.

Китерелгән хокукый җайга салу карала торган хокук мөнәсәбәтләренең мөрәҗәгать итүченең алты айдан соң транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алу хокукын раслау зарурлыгын күздә тоткан вакыт белән бәйле булуын күрсәтә. Бу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү өлешендә гамәлдә булуы мөрәҗәгать итүче гариза биргән айдан һәм әлеге түләүне билгеләү турында карар кабул иткәннән соң башланган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм югарыда күрсәтелгән алты ай эчендә дәвам итә дигәнне аңлата. Алты ай узганнан соң транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алуны дәвам итү максатларында мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслау зарурилыгын күздә тоткан әлеге хокук мөнәсәбәтләренең вакыт белән бәйле булуы әлеге социаль ярдәм чарасының адреслылык принцибын үтәүне тәэмин итү гарантиясе булып тора һәм аңа мохтаҗ гражданнарга ярдәм итү мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән аспектта аның хокукларын бозучы буларак карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацын, 2.1 пунктын һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктының конституциячеллеген тикшерүгә кагылышлы өлешендә әлеге эш буенча эш башкаруны туктатырга, чөнки мөрәҗәгать итүченең бу өлештә мөрәҗәгате мөмкин түгел.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

106-П **Татарстан Республикасы Конституция суды**

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН: «ҮЗ ЭШЕМНЕ, КЕШЕЛӘРНЕ, РЕСПУБЛИКАМНЫ ЯРАТАМ»

Финанс

Бу көннәрдә республика парламентында узган елгы бюджетны үтәү йомгаклары буенча фикер алышулар булды. Дәүләт Советы утырышында аны үтәү турында закон кабул ителде, комитетта быелгы 5 айда бюджетны үтәү йомгаклары каралды. Татарстан финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИННан газета укучыларга төп финанс документы үтәлеше турында сөйләвен сорадык.

:: Радик Рәүфович, узган елгы бюджетның ничегрәк үтәлүен кыскача гына тасвирлап бирсәгез иде.

– Гомумән алганда, уңышлы булды. Республикада төп макроикътисади күрсәткечләр буенча уңай динамика күзәтелде. Бу барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлар өчен керемнәр алуга уңай йогынты ясады.

Тупланма бюджетның керем өлешенә 411 миллиард сум керем күчерелде, шуның 336 миллиард сумы – салым һәм салым булмаган керемнәр. Татарстан үз керемнәре күләме буенча Россия субъектлары арасында җиденче урынга чыкты.

Республика бюджетына барлыгы 355 миллиард сум керем алынды, шуның 280 миллиард сумы – салым һәм салым булмаган керемнәр. Үзебезнең салым керемнәрендә табышка салым иң зур өлешне алып тора. Асылда аны нефть тармагы предприятиеләре кертә. Соңгы 6–7 ел эчендә салым иң зур күләмдә – 119,5 миллиард сум җыелды. Физик затлар керемenә салым әһәмияте ягыннан икенче урында тора. Икътисадта уртача хезмәт хакы арту нәтиҗәсендә салым кереме дә үсә.

Һәр салым төренә аерым тукталып үтмим. Аларның барысы да планлаштырылган күләмдә тупланды. Кабул ителгән финанс йөкләмәләренең барысын да үтәү мөмкинлеге булды, дигән сүз бу.

:: Димәк, планда каралган барлык чыгымнар үтәлгән. Шулай да нинди юнәлешләргә игътибар итәсе бар?

– Узган елгы бюджет, гадәттәгечә, социаль характерда булды: бюджет оешмалары һәм автоном учреждениеләрнең көйле генә эшләве тәэмин ителде, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә эш хакы вакытында түләнде (хезмәткәрләрең аерым категорияләренә «май указлары» буенча түләүләрне кертеп). Чыгымнарның 58,9 проценты социаль өлкә учреждениеләрен финанслауга бәйле. Тупланма бюджеттан – 234,4 миллиард сум, республика бюджетыннан 179,4 миллиард сум акча тотылды. 2021 елда Татарстан Республикасы тупланма бюджетының барлык чыгымнары – 398,1 миллиард сум, республика бюджеты чыгымнары 343,6 миллиард сум тәшкил итте.

Барлык чыгымнар Татарстан Президентының Дәүләт Советына Юлламасында куелган бурычларны тормышка ашыруга бәйле.

Мәгариф объектларын, сәламәтлек саклау учреждениеләрен, мәдәни үсеш һәм авыл мәдәният үзәкләрен, физик культура һәм спорт объектларын төзекләндерү, яңаларын төзеп файдалануга тапшыру игътибар үзәгенә алынды. Бүлеп бирелгән акча хисабына барлык дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең эшчәнлеге тәэмин ителде, планлаштырылган чаралар үткәрелде.

Дәүләт заданиесендә билгеләнгән индикаторлар һәр тармак эшенең сыйфат күрсәткечләре булып тора. Әлеге индикаторлар асылда барлык юнәлешләр буенча үтәлде. Монысы да эшчәнлекне, шулай ук бюджетны үтәүне уңай бәяләү булып тора.

:: Республикада инде байтактан салым ташламалары кертелде. Алар быел да гамәлдә булып килә. Дәүләт Советы утырышында ташламалар 2023 елга да озайтылды. Бу ташламалар кемнәргә һәм нинди күләмдә бирелә?

– Татарстанда кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итүгә зур игътибар бирелә. Шундый ярдәм чараларының берсе – салым салуның гадиләштерелгән системасы буенча салым ташламасы. Эшкәртү производстволарында, төзелештә, электр энергиясен, газ һәм су җитештерү-бүлү өлкәләрендә эшләүче оешмалар, хосусый эшмәкәрләр өчен салым ставкасы 5 процентка калдырылды. Әлеге категория буенча ташлама суммасы якынча 1,4 миллиард сум тәшкил итә.

Бакчачылык ширкәтләрен үстерү өчен социаль ташлама бирелә. Бу гомуми файдаланудагы милеккә салым түләүдән азат итә. Әлеге категория буенча ташлама суммасы 141 мең сум булды.

Шулай ук сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт ихтыяҗлары өчен файдаланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектлары да киметелгән салым ставкасын куллана. Ташлама халыкның сыйфатлы медицина ярдәменә ихтыяҗын канәгатьләндерү һәм физик культура, спорт белән даими шөгыльләнүчеләрнең санын арттыру максатында бирелә. Бу категория буенча ташлама суммасы – 176 миллион сум чамасы.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хөрмәтле Радик Рәүфович!

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, финанс органнары хезмәткәрләре, ветераннары Сезне «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены бирелү белән ихлас күңелдән котлый. Егерме ел дәверендә финанс министры вазыйфасын үтәп, Сез республика үсеше өчен күп көч куясыз, һәр мәсьәләне җентекләп тикшереп, төрле яктан уйланган карарлар кабул итәсез. Сездә булган тыйнаклык, җаваплылык, кешелеклелек безне сокландыра. Киләчәктә дә эшегездә уңышлар, нык сәламәтлек, гаилә бәхете телибез.

:: Узган елгы бюджет буенча барысы да аңлашылды. Әмма, мәгълүм булганча, бюджет өзлексез үтәлә. Быел аның үз үзенчәлекләре, үз кыенлыклары бардыр. 5 ай эчендә ул ничегрәк үтәлде?

– Соңгы елларда билгеле бер тирбәлешләр күзәтелә. 2019 елда барысы да тотрыклы булса, 2020 елда керемнәрне туплау авырга туры килде, 2021 елгы күрсәткечләр алдагы ике елдагыга караганда яхшырак булып чыкты. Быел 5 айда салым һәм салым булмаган керемнәр 173 миллиард сум тәшкил итте. Кайбер салымнар буенча уңай динамика күзәтелә. Гомумән алганда, бюджетны үтәү, тулаем илдәге кебек, киеренке шартларда хәл ителә.

Ни генә булмасын, бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакы, социаль түләүләр, пособиеләр үз вакытында бирелә, мәгариф, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау тармакларында һәм башка социаль тармакларда дәүләт заданиеләрен башкару өчен акча тулы күләмендә җибәрелә.

:: Радик Рәүфович, форсаттан файдаланып, финанс министры вазыйфасына билгеләнүегезгә 20 ел тулу уңаеннан котлап үтәсем килә. Шушы еллар эчендә сез укучыларыбызга бюджетны үтәүдәге катлаулы процессларны бәйнә-бәйнә аңлатып киләсез. Сезгә нык сәламәтлек, эшчәнлегегездә алга таба уңышлар телибез. Уңышларыгызның серләре белән дә уртаклашып үтсәгез иде.

– Аерым бер серләре юктыр дип уйлыйм. Үз эшемне, кешеләрне, республикамны яратам, вак-төяккә дә сөенә беләм, үземә йөкләнгән бурычларны сыйфатлы итеп башкарырга тырышам. Миңа ышанулары, ярдәмнәре өчен республика җитәкчелегенә, Татарстан Президентына, гаиләмә, туганнарыма, дусларыма, коллегаларыма рәхмәтлемен. Һәрбер кеше – үзенең керемнәре һәм чыгымнары буенча финанс министры. Барыбызга да керемнәре чыгымнарга туры килгән бюджет, нык сәламәтлек, тыныч күк йөзе телим!

Әңгәмәдәш – Диләрә СӘГЪДӘТШИНА

Ватан хакына

КОНТРАКТ БУЕНЧА ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘ КИТҮЧЕЛӘР: «БЕЗ ЯКЛАМАСАК, КЕМ ЯКЛАР?»

«Татар-информ»

Татарстаннан көн саен 10лап егетне контракт буенча хәрби хезмәткә озаталар. Билгеле булганча, республикада ике махсус батальон туплыйлар. Шунысы мөһим: егетләр шушы вакыт аралыгында элеккеге эш урыннарын саклап кала алачак. Шулай ук тагын бер мөһим шарт: Россия Оборона министрлыгы түләгән акчадан тыш, Татарстан Хөкүмәте республикадан киткән егетләргә бер мәртәбә 200 мең сум күләмендә түләү вәгъдә итә. Шуңа өстәп, солдатларның үзләренә һәм якыннарына күпсанлы ташламалар да каралган.

Контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пунктының өлкән инструкторы, прапорщик Виктор Никитин сүзләренчә, бүгенгә 400гә якын егет килешү төзергә өлгергән инде. «Бер айга якын махсус әзерлек узганнан соң, алар хәрби бурычларын үтәргә җибәреләчәк. Шул исәптән, Украина территориясенә дә. Контракт ким дигәндә дүрт айга төзелә. Аны озайтырга да мөмкин. Беркемне дә мәҗбүриләмибез, барысы да үз теләге белән китә», – диде ул.

Виктор Никитин билгеләп узганча, көненә 10лап егет, барлык тикшерүләрне дә узып, килешү төзи. Теләк белдерүчеләр, махсус хәрби операция башланган вакыт белән чагыштырганда, кимрәк булса да, шактый шалтырата икән. «Хатын-кызлар да бар. Әле бүген генә 54 яшьлек ханым шалтыратты. Тәҗрибәле терапевт, ярдәм итәргә тели. Хатын-кызлар күбесенчә медицина хезмәткәре яисә элемтәче булып уза бит хәрби хезмәтне», – дип сөйләде ул безгә.

Махсус операция башланганнан бирле 500дән артык Татарстан егете, контракт буенча хезмәт итүне сайлап, Украинага киткән. Узган ел белән чагыштырырлык та түгел. 2021 елда килешү төзүчеләрнең гомуми саны 1000ләп кеше булган. Үз теләкләре белән хәрби хезмәтне сайлаган егетләр белән бераз аралашырга да җай чыкты.

Чаллы егете Артур Сәлимовка – 33 яшь. «Мин гап-гади гаиләдә үстем. Хатыным һәм җиде яшьлек улым бар. 2012 елда чакырылыш буенча хезмәт итеп кайттым. Хәзер менә хәрби хезмәтемне контракт буенча дәвам итәргә телим. Мин илемне үз гаиләм кебек күрәм. Килешәсездер, гаиләдәге кешене барыбер яклыйсың һәм саклыйсың. Хаклымы ул, хаксызмы, аның турында башкалар нинди фикердә – алары мөһим түгел, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә. – Минем улым үсә. Әгәр аңа мин үрнәк күрсәтмәсәм, кем күрсәтер соң?»

50 яшьлек Улугбек Халматовның хәрби хезмәт тәҗрибәсе шактый бай. 1990–1992 елларда Литва, Рязаньда хезмәт итә. Путч вакытында Мәскәүдә Хөкүмәт йортын саклаучыларның берсе була. Чаллыга әйләнеп кайтып, берничә ел эшли дә 1999 елда, килешү төзеп, хәрби хезмәткә юл тота. Югославиягә барырга җыена, килеп чыкмый. Аның каравы Чечнягә барып чыга. Ягъни хәрби операциянең нәрсә икәнен яхшы белә ул. «Мин балалар йортында үстем. Балачагым да «сугышып» үтте. Ул чакта ук хәрби булырга хыяллана идем», – дип искә ала тәҗрибәле ир-егет.

Без якламасак, кем яклар? Улугбек Халматовның тормыш девизына әйләнергә өлгергән сүзләр бу. «Кыерсытылганнарны без якларга һәм сакларга тиеш. Ничек читтән карап тора алыйк ди? Хәрби ант биргән бит! Ике улым бар, аларга да үрнәк булырга тиеш мин».

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТЕЛӘК БУЛСА, ҖИҢӘСЕҢ!

Яшәеш

Табиблар әнә шулай ди. Әгәр авыру бик теләсә, гомерен дә озайта ала икән. Бу хакта Казан дәүләт медицина академиясендә узган «Сәламәт яшәү рәвеше аша өлкәннәрнең гомерен озайту» дип аталган «түгәрәк өстәл»дә сөйләштеләр. Баксаң, кеше организмының мөмкинлекләре зур икән. Җитмештә дә – егетләр, сиксәндә дә кызлар кебек яшәргә була, диләр. Казан дәүләт медицина академиясе директоры, профессор Рөстәм Хәсәнов та, тереләм дигән кеше максатына ирешә, дип белдерде.

«Татар-информ»

– Минем бер танышым бар. 86 яшендә булса да, әле дә физик күнегүләр ясый. Буыннарын алыштырыр вакыт җиткән, әмма ул киреләнә. Кирәкми дип баш тарта, – ди ул. – Элекке вакытны искә төшерик. 50 яшендә инде кешеләр бабай, әби иде. Ә хәзер бу вакытта яңа тормыш башлана гына әле. Бар да кешенең үзеннән тора. Кемдер, пенсиягә чыгып, мин картайдым, дип утырырга, икенчесе актив тормыш рәвеше алып барырга мөмкин.

Рөстәм Хәсәнов 88 яшьлек әбисен дә искә төшерде. Бервакыт әнисенең сеңлесе зарлана икән. Казанга килә алмыйм, олыгайдым, 80 бит инде миңа, дигән. Аңа каршы апасы, минем янда әле син япь-яшь бит, дип сүгеп ташлаган. Табиб, картаю турында уйламыйча, тормышны яратып яшәргә кирәк, ди. Мисалга чит ил кешеләрен күрсәтә. Бервакыт эш белән Америкага бара ул. Монда слет уза. Караса, затлы-затлы машиналар килеп туктый. Ә алардан тешләре куелган, битләре тарттырылган, аяк буыннары алыштырылган картлар чыга икән. Иң яшенә 80 яшь, ди.

– Иң кызыгы: бу кешеләр, слетта чыгыш ясаганнан соң, төшке аш ашадылар да пыр туздырып биеп кайтып киттеләр. Үзләре машина да йөртә әле. Шул чакта шаккатып калган идем. Хәзер менә алар дөрес эшләгән дип уйлыйм. Безнең өлкәннәр дә шулай яшәргә тиеш, – ди ул.

Очрашуда, сәламәтлекне кайгырту кешенең бары тик үзеннән тора, дигән фикер күп кабатланды. Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова да шулай дип белдерде.

– Сәламәтлегенең 60 проценты – кешенең үз кулында. Табиблар диагноз куя, дәвалый. Әмма терелү өчен яшәү көче кирәк. Яшим дигән кеше яши. Нинди генә медицина оешмасы төземә, нинди генә белгечләр эшләмәсен – аякка басу-басмауны авыру үзе хәл итә, – ди ул. – Аннары шул ягы да бар: совет чорында туган балалар эшсез тора алмый. Баксаң, ял итә белергә дә кирәк икән. Шунысын да онытмыйк.

Пандемия чорында өлкәннәрнең саны кимегән. Соңгы мәгълүматлар буенча, ирләрең уртача гомер озынлыгы – 67, хатын-кызныкы 77 яшь икән. Ирләрне сакларга кирәк, ди Казан дәүләт медицина академиясе профессоры Әфгат Галиуллин.

– Авыл җирендә торучылар каладагыларга караганда озаграк яши. Шәһәрдәге ыгы-зыгы, тавыш, һаваның чиста булмавы сәламәтлеккә начар йогынты ясый. Чирмешән, Яңа Чишмә, Актаныш, Кама Тамагы районнарында өлкәннәр арасында үлем-китем күбрәк. Гомерне озайтыр өчен пенсия яшендәге кешеләргә медицина ярдәме күрсәтелә торган үзәк ачарга кирәк, – ди ул.

Мин картайдым инде, дияргә дә ярамый икән! Күңелдә гел яхшы уйлар гына булсын. Бу җәһәттән музыка терапиясенең файдасы әйтеп бетергесез. Кешеләргә үзенең кирәклеген тою да терелергә ярдәм итә. Әмма психотерапевт Марина Белоусова, халык гел борчылып яши, дип кисәтә.

– Күңелсез яңалыкларны тыңламаска кирәк. Ә без гел начар хәбәр эзлибез. Ярату, шатлык кебек хисләр турында оныттык. Өлкәннәр матур планнар корып яшәргә тиеш. Мисал итеп Америкадагы бер ханымны китерәм. Ул 60 яшендә, очучы буласым килә, ди. Максатына да ирешә: 66 яшендә укып бетереп, беренче тапкыр күккә күтәрелә. 83 яшенә кадәр 7 тапкыр оча әле ул. Бу мисал кешенең мөмкинлеген күрсәтә, – ди ул. – Үземнең пациентлардан чыгып, шуны әйтә алам: авылда эте, мәчесе, тавыгы, сыеры булган кешеләр тизрәк дәваланып, савыгып кайтып китә.

Татарстанның ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков сүзләренчә, лаеклы ялга чыккач та, кеше үзенең кирәклеген тоярга тиеш. Моның өчен кулдан килгәнне эшлиләр. Илкүләм проектлар да ярдәм итә.

– Актив яшәү гомерне озайта. «Өлкән буын», «Спорт – яшәү нормасы» федераль проектлары шундый максат куя да инде, – ди ул. – Безнең оешма тарафыннан төрле проектлар алып барыла. Өлкәннәр бик теләп «Балкыш» фестивалендә, «Ветераннар иҗаты» дигән бәйгедә катнаша. Актив яшәгән кеше авыруларын да, даруларын да оныта.

Дару дигәннән, аларны физик күнегүләргә алыштырырга кирәк. Казанның Вахитов районының ветераннар советы рәисе Генрих Бердников, бары тик сәламәт яшәү рәвеше алып барып кына гомерне озайтып була, дигән фикердә.

– Дөрес туклану, дөрес йөрү, дөрес сулау, табигать кочагында ял итү кешегә көч бирә. Үз-үзеңә ышанып яшәргә кирәк. Мин инде сиксәндә, дип утырганчы, яшегезне онытып, селкенә башлагыз. Хәрәкәт кирәк. Гомер озынлыгын яратып башкарган эш тә озайта. Кыскасы, бар да үзебездән тора. Иренмик, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ШӘҖӘРӘ

«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

Гөлсирә Шәрифуллина

Тарих янәшәдә

Чирмешән районындагы Туймәт авылында төрле милләт кешеләре яши. Дөрес, ул үзе – саф татар авылы. Мәктәптә дә татарча укыйлар. Әмма кирәк икән, русча да шәп сөйләшәләр.

Шушы авылга килен булып төшкән чуаш кызы Иринага, шуңа күрәдер инде, бер дә кыен булмаган. «Ирем дә, күршеләр дә минем белән рус телендә сөйләшергә тырыша. Балалар мәктәптә татарча укыйлар. Өйгә кайткач, рус теленә күчәләр», – ди ул.

Әмма сүзебез ул хакта гына түгел әле. Ирина Мортазина гаиләсе белән инде күп еллар нәсел-нәсәбен барлый, быел «Без тарихта эзлебез» фестиваленең зона ярышларында җиңү дә яулаганнар. Бәйрәмдә жюри әгъзалары игътибарын бу гаиләнең, нәкъ менә төрле милләт вәкилләре булып, барысын да тигез күреп, дус, тату яшәүләре җәлеп иткән.

– Бер карасаң, тормыш нәкъ кинодагы кадрлар кебек бит ул, – ди Ирина. – Безнең гаиләдә дә барысы да гади генә кебек. Ачыкланган кадәренчә, бишенче буын нәсел җебе Сембер губернасындагы чуаш авылында туып үскән әбиемнән башлана. Башка милләтләр белән катнашу әниемнең әбисенә килеп төртелә: ул рус егетенә кияүгә чыга.

Әбисе сөйләгәннәр буыннан буынга күчкән. Шуннан ишетеп белә Ирина: Ванчиковлар гаиләсе Түбән Кармалкага беренче тапкыр 1790 нчы елларда күченеп килгәннәр. Әмма төпләнеп яши башлаулары 1812 елга туры килә.

– 1893 елгы бабам Константин шушы авылда туып үсә. Надя исемле үзе кебек үк авыл кызына өйләнә. Язмыш кырыс була: алтынчы балалары тугач, әбием үлеп китә, алты бала бабам белән әбиемнең әнисе Арина кулында кала. Ул гына да түгел, сугыш башлануга, бабам фронтка китә, аңа өйләнеп кайтырга насыйп булмый. Шул ятим балаларның берсе – әтием Василий. Тормыш акрын гына үз эзеннән бара. Мин инде күпбалалы рус гаиләсендә үстем. Әтием кырык елдан артык терлекчелек өлкәсендә эшләде, әнием Анастасия сыер савучы иде. Алар бик тырышып хезмәт куйдылар: Мактау кәгазьләре дә, бүләкләре дә бик күп, Хезмәт ветераны исеменә дә лаек булдылар. Алты бала үстерделәр, 12 оныклары, аларның тагын өч балалары бар, – дип, хәтер йомгакларын сүтә Ирина.

Ул үзе авылда 10 сыйныфны тәмамлаганнан соң Самара өлкәсендәге Тольятти шәһәренә китеп бара. Сагынуына чик-чама булмый: техникум тәмамлап, электромонтер, кранчы һөнәрләрен үзләштергәннән соң авылга кайта да күп сайланып тормый, әнисе кебек, сыер саварга керешә. «Шәһәрне яратмадым мин», – ди ул. Белеме булгач, барыбер күреп алалар үзен: мәктәпкә хуҗалык эшләрен алып барырга чакыралар. Язмыштыр инде, кыз күрше Туймәт авылындагы Җәмил исемле татар егетенә кияүгә чыга. Тел дә башка, дин дә башка бит инде. Авырлыклар булмый калмагандыр.

– Бик яхшы каршы алдылар. Авыл халкы белән бик тиз уртак тел таптым, – дип искә ала Ирина ул вакытларны. Аннары: «Баштарак каршылыклар булгаладыр кебек инде, әмма мин бик тиз яхшы киленгә әйләндем», – дип тә өстәп куя. Дүрт бала тәрбияләп үстергәннәр, ике оныклары да бар. Ире электрик булып эшли, үзе – мәдәният өлкәсендә.

Иринадан катнаш гаиләдә тыныч, тигез яши алуның серләрен сораштырам.

– Ике якның да традицияләрен, гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә кирәк, – ди ул. – Фестиваль өчен әзерләнгән чыгышта да шуңа басым ясарга тырыштым. Мәхәббәт, татулык булган җирдә бернинди киртәләр дә булмый. Бер-береңне аңлап яшәргә генә кирәк. Мин ислам дине кануннарын хөрмәт итәм, ирем православие динен игътибарсыз калдырмый. Ифтар мәҗлесенә дә бик яратып әзерләндем. Ирем белән улым барлык күршеләрне, дусларын чакырдылар. Пасха бәйрәменә минем яктан кунаклар килде. Фестивальдәге чыгышны да нәсел җебенең очында торган чуаш әбиебезне искә алудан башладык. Башта чуаш ансамбле, аннары руслар, татарлар чыгыш ясады.

Мортазиннар гаиләсе фестивальдә беренче тапкыр гына катнашкан әле. Әмма киләчәктә дәвам итәргә исәпләре.

– Бу эш белән балалар шөгыльләнер инде. Ерак әбибабаларының төрле милләттән булулары аларны бигрәк тә кызыксындыра. Тарих үзе янәшәдә бит. Әллә кайларга барып эзләнәсе дә юк, – ди Ирина бу җәһәттән.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЙОСЫФЛАР КОЕСЫЗ ҮСМИ

Премьера

«Кыйссаи Йосыф» – бер дистә елдан 800 еллыгы бәйрәм ителәчәк борынгы шаһ әсәребез. Туган урыны һәм килеп чыгышы төгәл билгеле булмаган Кол Гали Коръән һәм Тәүрат өчен уртак булган мәңгелек сюжетка мөрәҗәгать итә. Моның өчен билгеле бер дәрәҗәдә кыюлык та кирәк булгандыр.

karievteatr.ru

Кариев театрында яңа «Йосыф»ны карагач, милли классика булудан бигрәк, беренче чиратта дөнья-күләм классика булган һәм изге текстларга нигезләнгән сюжетка алыныр өчен рухи яктан гаҗәеп әзерлекле булырга кирәклегенә тагын бер кат инандым. Бу уңайдан диннәр тарихын һәм теологияләрен өйрәнүче буларак кайбер күзәтүләрем белән уртаклашасым килде.

Кариев театры спектакльләренә хас булганча, музыка белән яктылык спектакльнең аерым геройлары булыр дәрәҗәдә әзерләнгән. Алар искиткеч югары кимәлдә башкарылган; хореография дә иң шәп тәэсирләр калдыра. Пластика сүз белән әйтеп бетерелмәгәнне яки ярамаганны җиткерә. Гомумән, барлык элементларны берләштергәч, гаҗәеп тамаша килеп чыга, бу картина күңелдә кала һәм урыны-урыны белән чыннан да соңгы елларда Голливуд чыгарган иң мавыктыргыч тасмалар белән дә ярыша ала.

Йосыф сәүче тарихы – кешелекнең иң зур дошманы Иблискә каршы бара торган мәңгелек көрәшнең бер эпизоды ул. Спектакльдә туганнарның гөнаһта берләшү эпизодлары – зур ачыш, шайтаннәфеснең даими пышылдауларын кара тасмалар аша күрсәтү дә бик отышлы чыккан. Гомумән, шайтанилыкның күзгә аермачык күренә торган образ аша бирелүе аның даими мәкерле эшен яхшы аңлата. Режиссер, Кол Гали традициясен дәвам итеп, яһүд милләте тарихына төрки-татар элементларын да кертә – сабый Йосыф белән Ибнеәмин Сабан туе уеннарында күңел ача. Мөнәҗәтләр спектакльне баета, ә йөзе һәм халәте белән Йосыфның тасвирламасына туры килгән актер – режиссерның янә бер ачышы.

Шулай да, бихисап «әмма»ларсыз да мөмкин түгел. «Йосыф» – амбициоз проект, ә инде чыганагы поэма гына түгел, Коръән дә дип бирелсә, җаваплылык меңләтә арта.

Спектакльдә Мисыр темасы никтер карикатура рәвешендә күрсәтелә, әйтерсең лә, режиссер тамашачыны кызгана. Мисырдагы рәсем техникасы кешеләрне профильләре белән сурәтләсә дә, мисырлылар яннары белән йөрмәгәннәр дип аңлатасы килә никтер. Мисыр фиргавене исә шундый мескен ки, мондый фиргавен белән ачлык, ялангачлык, сугыш киләсен көт тә тор (монысы, бәлки, режиссерның тарихи вакыйгаларга, Мисырның гиксослар тарафыннан яулап алынуына кинаяседер). Шуны искәртик: Йосыф галәйһиссәлам – Коръән яки кыйссалар «персонажы» гына түгел, ә тарихилыгына дәлилләр бик күп булган, моннан 3500–3800 еллар элек яшәгән шәхес. Ул яшәгән мохитне карикатура формасында сурәтләү шикле тоела.

Спектакльнең башы тетрәндергеч булса да, аның финалы, кызганыч ки, зәгыйфь, чөнки явызлык, ахыр чиктә, бик гади рәвештә гафу ителә: әйе, Йосыф чак кына бәргәләнә, әмма Зөләйхага шәһвәте белән көрәшү өчен аңа күбрәк вакыт кирәк иде, ә монда аны коточкыч сынауларга дучар кылган агаларына ул бик йомшак мөгамәләдә. Бу шулай булырга тиештер дә, чөнки ахыр чиктә ул – пәйгамбәр, ул йомшак күңелле. Әмма Йосыф тарафыннан гафу ителер алдыннан, моңарчы гөнаһта, хөсеттә берләшкән туганнарның да күңелләре йомшарырга, бәргәләнергә, аларны ни дә булса газапларга тиештер бит? Аларның минутлык кына вөҗдан газап чигүләре берни түгел.

Йосыф боларны «сез мине ачулы дисездер инде, тик мин сезне гафу итәм» дигән сыман җиңел генә кичерә дә куя. Ни өчен шулай соң? Чөнки спектакльдәге Йосыф, тарихи-легендар Йосыфтан аермалы буларак, Ягъкуб каршында тәгәрәп үскән бала булудан беркайчан да туктамый, ул һаман уйнау-көлүен дәвам итә. Режиссер пәйгамбәрлек тарихын бәян итәргә алынган, әмма без Кол Гали Йосыф Сиддыйк дип атаган тугрылыклы пәйгамбәрне, Бәни Исраил кавемен бизәгән хикмәтле шәхесне күрмибез. Алдыбызда – Иосиф Прекрасный, ул шаян, ул наян, газап кичерсә дә, көрәшсә дә, ул барыбер бала булып кала (ул хәтта кайвакыт Камыр батыр булып кала).

Вәләкин пәйгамбәрләр – бала түгел; пәйгамбәрләр шаярганда да җитди, чөнки алар кеше белмәгәнне белә, алар Җәбраил аша Бердәнбер белән аралаша. Аның гаурәтен ачу никадәр урынлы иде икән? Йосыф ни өчен түрә булуына сөенә дә, бу зәгыйфьлеге өчен җәза алмый (хата – җәза – тәүбә диалектикасы мондый сюжетларның нигезендә тора бит)? Спектакль Йосыфының шәхес һәм пәйгамбәр буларак үсешен коесызлык чикли: Библия, Коръән һәм Йосыф китабыннан аермалы буларак, тамашада Йосыф бу сынаудан котыла. Әмма нәкъ шушы сынау – аның беренче тәүбәсе; шул коеда сабый Йосыфтан хикмәт иясе ясала. Кое вакыйгасын – гаҗәеп экзистенциаль мизгелне, әверелешне, инициацияне бик дулкынландыргыч итеп күрсәтеп булыр иде. Нәкъ шушы булмаган эпизодта тамашага җитмәгән иң мөһим элементны – Илаһилыкны күрсәтеп булыр иде. Гомумән, спектакльне әзерләгәндә фәнни һәм теологик консультант белән эшләү җитеп бетмәгән дип әйтәсе килә.

«Әмма» вә «тик»ләрне игътибарга алмаганда, «Йосыф» – бик матур спектакль, тамашачыларның күбесе аннан бик хикмәтле уйлар белән баеп кайтачак. Вәгазьләнү өчен дә бу – бик сыйфатлы материал. Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына һәм «Кыйссаи Йосыф» әсәренең 2023 елда билгеләп үтеләчәк 790 еллыгына Кариев театры зур бүләк ясады.

Айдар ШӘЙХИН

РУС ТЕЛЕННӘН 100 БАЛЛ ТУПЛАГАН РАЯН ШАКИРОВ:

«СЫЙНЫФТАШЛАРЫМА ДА ДОГА КЫЛДЫМ»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Безнекеләрне бел!

Биектау районының Дөбьяз мәктәбе укучысы Раян Шакиров рус теленнән имтиханда 100 балл туплаган. Егет вузга укырга керү теләге белән дә янмый, технигумга керсә дә риза. Чама хисен белгәнгәме, югары балларга да омтылмаган. Авыл мәктәбендә укыган егет әлеге нәтиҗәләргә ничек ирешкән?

Узыгыз, кызлар!

Без килгәндә, Раян Әтнә районында яшәүче бабасында кунакта иде. Печән әзерләргә булышырга барган икән. Андагы эшен тизрәк бетереп, мәктәпкә безнең белән очрашырга кайтырга да вакыт тапты. Без ул арада аның сыйныф җитәкчесе, рус теле укытучы Миләүшә Хәйруллина белән укучылары һәм Раян турында гәпләшеп алдык. Быел мәктәпне 6 укучы тәмамлаган. Алар тәртипле, тырыш һәм белемгә омтылучан булуы белән аерылып торган. Миләүшә апалары һәрберсен мактап телгә алды. Арада республикада узган фәнни конференцияләрдә катнашучылар да бар. Бервакытта да, бу эшне ул эшләсен, мин түгел, дип бер-берсенә аудармаганнар. Мин булмаса, кем? Сыйныф әнә шул кагыйдә буенча яшәгән.

– Раян бервакытта да сыйныф ишегеннән беренче булып кермәде. Башта кызларны, укытучыларны уздыра иде. Имтихан бирү пунктында мәктәп капкасын ачып, сыйныфташ кызларын кертеп җибәрде дә шунда басып калды. Баксаң, мин килгәнне көтеп тора икән. Аларны озата барган идем. Шуннан соң гына үзе үтте. Бик итагатьле, төпле бала. Гаиләдә дин белән тәрбияләгәнгә шулайдыр, – ди Миләүшә Фәтхерахман кызы.

Бервакыт егет укытучысыннан: «Апа, тәнәфестә мәчеткә җомга намазына барыйм әле», – дип сораган. Ул нәрсә дип әйтергә белмичә аптырап калган. «Мәктәптә берәр буш бүлмәдә генә укый алмыйсыңмы соң?» – дип тәкъдим иткән. «Апа, монда уку җомга намазы булмый инде ул. Аның бөтен мәгънәсе – мәчеттә уку», – дигән Раян.

Егет бар уңышын Аллаһ ярдәме дип саный. Намаз укыган саен сыйныфташларына да дога кылган. Имтиханнарын яхшы балларга бирүен теләгән. Теләге кабул булган: барысы да сынауларда югары баллар туплаган.

Репетитор кирәкми

Миләүшә Хәйруллина әлеге мәктәптә 1986 елдан бирле эшли икән. Аңа кадәр район чигендәге Яңавыл авылында укыткан. Зур мәктәптә эшлисе килә дип, Дөбьязга килгән.

– Моңа кадәр 100 балл туплаучы укучым юк иде әле. Бик еш кына 98 балл була, әмма берничә балл җитми кала иде. 2018 елда 23 укучы чыгардым. Шуларның 15е имтиханда – «5ле», калганнары – «4ле», бары берсе генә «3ле» алган иде. Быелгы чыгарылыш сыйныфында уртача балл – 80. Репетитор яллаган берәү дә юк. Без үзебез өйрәтәбез. Балалар саны аз булгач, иркенләп шөгыльләнергә вакыт кала. Башта теманы аңлатам, аннан биремнәр эшлибез, хаталарга игътибар бирәбез. Нәтиҗәгә әнә шулай адымлап ирешәбез. Тырышып укып, өстәмә шөгыльләнүчеләр яхшы күрсәткечләргә ирешә, – ди 42 ел стажлы укытучы.

Укытучы фикеренчә, БДИ абитуриентларга ил, республика вузларына керү өчен юл ача. Белем бер системага туплана. Монысы әйбәт, тик укучы өчен – зур борчу. «Белемне бәяләми дип әйтеп булмый. Ярар, тест өлешендә кагыйдә белү кирәк, кысадан чыкмыйсың. Инша өлеше дә бар бит. Анда укучы үз фикерен белдерергә, текст төзү осталыгын күрсәтергә тиеш», – ди Пушкин телен укытучы.

Мин даһи түгел

Раян бары математика һәм рус теле сынауларын гына тапшырган икән. Бирә алмыйм дип шикләнгәч, өстәмә имтиханнан баш тарткан. Кая баруымны төгәл генә әйтә алмыйм, бәлкем, медицина юнәлеше булыр, ди.

– Авырлыклар да туды, аннан башка булмый. Укытучылар безгә, көн саен, ярты сәгать булса да, имтиханга әзерләнегез, дип өйрәтте. Атна буе өйрәнмичә, шимбә, ял көнендә 5–6 сәгать укып утырудан мәгънә юк. БДИ нәтиҗәсен яхшы булыр дип көткән идем. Укытучым Миләүшә апага бик зур рәхмәт. Барыбызны да гел мактап торды, терәк булды. Бер мәртәбә дә куркытмады, сүкмәде. Миләүшә апа кебек укытучы булганда, репетитор кирәкмени?! Ул бик җайлы итеп аңлата, – диде Раян Шакиров.

100 балл иясе сынауга әзерләнәм дип, үзеңне сындыру, көнгә биш сәгать кенә йоклау дөрес түгел дип саный. Саф һавада йөрү, тиешенчә йоклау, кыскасы, баш миен ял иттерү кирәк. Аның әйтүенчә, имтиханга әзерләнү өчен көнгә бер сәгать тә җитә. Үзе ул куркуга бирешә торганнардан түгел. Күңел халәте аның өчен барыннан да мөһимрәк. Бары тынычлык белән генә бәрәкәткә ирешеп була. Борчылганда, күбрәк хаталар килеп чыгачак. Раян әнә шулай ди.

Сынау нәтиҗәсен сыйныфташлары арасында Раян иң соңыннан караган. Сыйныф җитәкчесе белсә дә, сер саклаган. Раян, балларыңны кара инде, сине көтеп торам, дигәч: «Апа, җитәрлеге булгандыр инде», – дип әйткән. Нәтиҗәсен белгәч: «Миләүшә апа, минем күрсәткечләр, бераз булса да, күңелегезне күтәрдеме?» – дип язып җибәргән. «Син мәктәпнең генә түгел, район данын да күтәрдең», – дигән аңа укытучысы.

Раян имтихан балларын карарга ашкынып тормаган. 100 үк булмаса да, 90нан югарыдыр дип өметләнгән. Нәтиҗәсен күргәч, аптырап ук киткән. Татар мәктәбендә укыган гади укучылар да 100 балл туплый ала. Моның өчен даһи булу кирәкми, тырышлык та җитә. Егет әнә шуңа инанган.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 285

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.)**

16+